ХУҖАСЫЗ АВЫЛ

Бишмунча халкы җирле үзидарә башлыгын көтә

> 6

КҮЗ ЯШЕ

Фигуралы шуучы Камилә Вәлиевага бәйле карар нинди уйларга этәрде?

> 15

ФЕРДИНАНД СӘЛАХОВ:

«Уйлый торган тамашачы ул – куркыныч тамашачы»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 15 (29175) | Җомга | 2 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131



ru.freepik.com

АКЫЛ САТУ

КӨНКҮРЕШ ТЕХНИКАСЫ КИБЕТЛӘРЕ КАБАТ ҖАНЛАНГАН

Былтыр илдә сатылган һәр бишенче плитә – Белоруссиянеке, ә һәр өченче телевизор – Кытайныкы. Европа брендлары илдән киткәннән соң, бушап калган кибет киштәләрен Кытай, Төркия һәм Белоруссиядә җитештерелгән көнкүреш техникасы яулап алды, ди белгечләр. Узган ел сатылган барлык техниканың кырык проценты әлеге илләрдән кайтартылган товарларга туры килгән. Ят исемле кер юу машинасы, суыткыч сатып алу куркыныч түгелме? Кытай чәйнегенең сыйфатына күрә бәясе туры киләме? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

> 5

Ишетми калмагыз

Татарстанда соңгы 6 елда табигатьне саклау максатында 60,5 миллиард сум тотылган. Бу миллионнарча кешенең яшәү шартларына уңай йогынты ясаган. Экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков әйтүенчә, төбәгебездә сәнәгать предприятиеләре әйләнә-тирә мохитне саклауның мөһимлеген аңлап эшли. Фән исә экология мәсьәләләрен хәл кылуга ярдәм итә.
Сүз уңаеннан, Татарстанда үткәрелгән сораштыру барышында респондентларның 95 проценты, күченү мәсьәләсен караганда, экологиянең торышын исәпкә алачакларын әйткән. Тагын 71 проценты чамасы төбәгебездәге экологик вазгыятьне, уртачадан югарырак дәрәҗәдә, дип бәяләгән.

Ел башында Татарстанда эшсезлек күрсәткече рекордлы дәрәҗәдә кимеп, нибары 0,2 процентка калган. Кайбыч (0,05%), Тәтеш (0,05%), Лаеш (0,06%), Яшел Үзән (0,06%), Алексеевск (0,07%) һәм Лениногорск (0,08%) районнарында бу күрсәткеч тагын да түбәнрәк. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, Яңа Чишмә (0,43%), Түбән Кама (0,42%) һәм Югары Ослан (0,33%) районнарында, шулай ук Казанда (0,27%) эшсезлек республика буенча уртача күрсәткечтән зуррак.

Татарстан бәхетле кешеләр саны буенча өченче урынга чыккан. Сораштыру нәтиҗәләренә караганда, республикада яшәүчеләрнең 11 проценты үзен 5 баллга (иң югары балл) бәхетле итеп сизә. «Сенат-информ» язганча, әлеге күрсәткеч бары тик Екатеринбург һәм Свердловск өлкәсендә (22%), шулай ук Түбән Новгородта (16%) гына бездәгедән югары. Татарстанда яшәүчеләрнең тагын 33 проценты үз бәхетен 4 баллга бәяләгән.

Республикада февральнең беренче декадасында һава температурасы нормадан 7 градуска югарырак булачак. «Якын арада һава температурасы нульгә якынлашачак. Димәк, кар эреячәк. Ләкин су басу көтелми, чөнки әле кышкы ай бит», – ди КФУ метеорологы Тимур Әухәдиев.
Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә һәм якшәмбе – 3–4 февральдә юеш кар, кайбер районнарда буран көтелә. Көндез термометрның терекөмеш баганасы 0…–6 градус күрсәтәчәк. Төнге сәгатьләрдә –3…–10 градус.
Синоптикларның башлангыч фаразлары буенча, киләсе атна башында – 5–6 февральдә болытлы һава саклана, юеш кар явачак. Көндез һава температурасы 0…–5, төнлә –3…–8 градус чикләрендә тирбәләчәк. Сишәмбе – 6 февральдә көндез 0…+1 градус. Юлларда – көчле бозлавык.

Районнарда ни хәлләр?

Чаллы

Чаллы эшмәкәре, хәйрияче Рөстәм Гатин Лисичанскидан ике баланы Чаллыга алып кайтты. Алар «Безнең балалар. Лисичанск – Чаллы» проекты кысасында дәваланачак. «Малайлар хәзерге вакытта әниләре белән «Жемчужина» шифаханәсендә, аларга җитди диагнозлар куелды. Берсенең авариядән соң сәламәтлеге какшаган, икенчесендә – аутизм», – ди Рөстәм Гатин. Әлеге проект кысасында барлыгы 12 баланы алып кайтканнар. Аларның унысы тиешле дәвалануны узган инде. «Бер кыз хәтта аягына басып йөри башлады», – ди хәйрияче.
(«Шәһри Чаллы»)

Бөгелмә

Карабаш авылында җирлекнең танылган ат тотучыларына багышланган «Аударыш» турниры узды. Әлеге традицион турнир ат өстендә көрәшүдән гыйбарәт. Чараны татар токымын үрчетүче Фәрит Нәбиуллин оештырды. Аның сүзләренчә, элек ат чабышлары елына берничә тапкыр узган, атларда көрәш тә популяр булган. Карабашта ел саен уза торган турнирның биелгысында Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорск, Тукай, Ютазы, Алабуга районнарыннан килгән 25 кеше катнашты. Быел тәүге мәртәбә 12–14 яшьлек малайлар понига утырып көрәшеп карады. Тамашачылар өчен исә «Аркан ыргыту», «Таш ату», «Багана белән чабу» кебек уеннар оештырылган иде. Теләгән һәркем атта һәм понида йөри алды.
(«Бөгелмә-информ»)

Ютазы

Кече Урыссу халкы авылга нигез салынуның 100 ел тулуын билгеләп үтәчәк. Бу хакта Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Рамил Вәлиев халык җыенында хәбәр итте. Кече Урыссу авылының 100 еллык юбилее кысасында авыл җирлеге башлыгы авылга керү юлында стела урнаштырырга ярдәм итү мәсьәләсен күтәрде. Эшне быел башкару планлаштырыла.
(«Ютазы таңы»)

Кукмара

Кукмараның беренче гимназиясендә шушы белем йортында укыган, махсус хәрби операциядә гомере өзелгән Илназ Гайфиевның исемен мәңгеләштерделәр – хәтер тактасы куйдылар. Аны ачу тантанасында район хәрби комиссары Альберт Гомәров, район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Айгөл Әхмәтшина, Илназның әнисе Гөлнур ханым һәм башкалар чыгыш ясады. Узган елның октябрендә Харьков өлкәсенең Купянск районы территориясендә хәрби бурычларын үтәгән вакытта егетнең гомерен ядрә кыйпылчыгы өзә, ике иптәше, яраланып, госпитальгә эләгә.
(«Хезмәт даны»)

БЕЗНЕҢ ЮЛ

Түләүле юллар, авылга хас тыйнаклык һәм җәмәгать транспортына бәйле шикаятьләр. Башкалада Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының еллык коллегия утырышы узды. Чарада катнашкан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов юлчыларны шелтәләде дә, мактады да.

– Былтыр Татарстанда юл эшләренә, зур проектлар тормышка ашырылуны да исәпкә алып, 248,7 миллиард сум акча тотылды, – диде Фәрит Хәнифов. – Бу – бик зур уңыш һәм республиканың, илнең мөмкинлекләре күрсәткече. Моңа Россия Президенты Владимир Путинның стратегик карарлары, Ил Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин командасының һәм федераль заказ бирүчеләрнең зур эше бәрабәренә ирештек. Ярдәм күрсәткәне өчен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка да зур рәхмәт.

Билгеле ки, узган ел М12 «Казан – Мәскәү» автомобиль трассасын кулланышка тапшыру белән тарихка кереп калачак. Әлеге эштә республика юлчыларының да өлеше зур. Олы юлны өч елдан да кимрәк вакыт эчендә кулланышка тапшырдылар. Озынлыгы 800 чакрымнан да артык тәшкил иткән түләүле трассаның 142 чакрымы Татарстанга туры килә. Сүз уңаеннан, М7 һәм М5 трассаларын тоташтырачак Шәле – Баулы юлының бер өлеше булган Алексеевск – Әлмәт түләүле юлын быел кулланышка тапшырырга вәгъдә иттеләр. Тагын да алга китеп, Казанда төзелүче Вознесение трактының икенче өлеше дә түләүле булачак. Бу хакта коллегиядә Рөстәм Миңнеханов әйтте. М7гә чыгучы әлеге юлны дәүләт-шәхси хезмәттәшлек нигезендә төзеп бетерәчәкләр.

Республикада автомобиль юлларының гомуми озынлыгы 40,4 мең чакрым тәшкил итә. Шуның 1,3 мең чакрымы – федераль, 13,5 мең чакрымы – төбәк, 25,6 мең чакрымы исә муниципаль юлларга туры килә.

Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская исә яңа юллар төзү белән бергә ттән, аларның сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында да онытмаска киңәш итте.

– Узган ел Татарстанда яшәүчеләрдән юл хуҗалыгы һәм транспортка бәйле 33 меңгә якын шикаять теркәлде. Халык күбрәк юлларны карап тору, ремонт, җәмәгать транспортына бәйле кыенлыклар турында хәбәр итә. Мөрәҗәгатьләр Казан, Чаллы, Әлмәт кебек зур шәһәрләрдә күбрәк, – диде ул.

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың ун районына 40 автобус тапшырды. Мартка кадәр тагын 79 автобус кайтып җитәчәк.

Сәрия Сабурская шуны да әйтте: баксаң, халыкның нибары 10 проценты гына юл хуҗалыгы һәм транспортка бәйле шикаятьләрне хәл итү тәртибеннән канәгать икән. Мисаллар да китерде ул. «Халык контроле» системасында 2014 елдан бирле хәл ителмәгән сораулар бар икән. Өстән төшсен өчен генә эшләнгәннәре дә очрый. Мәсәлән, юл чатына ут баганасы куюны сорап мөрәҗәгать иткән берәүгә светофор кую турында җавап биргәннәр. «Сез мәсьәләне хәл итәсезме, әллә хат язышу белән генә шөгыльләнәсезме?» – дип мөрәҗәгать итте ул залда утыручыларга.

Кыш көне халыктан килеп ирешкән моң-зарлар арта. Гыйнвар аенда гына да карны җыештыруга бәйле 3,8 меңнән артык шикаять килгән әнә. Быелгы кыш тәмам теңкәгә тигәнне Рөстәм Миңнеханов та белә.

– Быелгы карлы-буранлы кыш мондый шартларда юлларны тәртиптә тотарга әзер түгел икәнебезне күрсәтте. 20–30 ел элек мондый карлы кышлар гадәти хәл иде югыйсә, – диде Татарстан Рәисе.

Аның сүзләренә караганда, Казан халкы гына зарланмый, республика районнарында да шул ук хәл. «Шикаять белдерүләре хак. Аклану урынсыз. Мәсьәләне хәл итү юлларын эзләргә кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Рәисе халыкның тагын бер авырткан җиренә тукталды. Ул да булса – җәмәгать транспорты.

– Татарстанда җәмәгать транспорты эшенә бәйле шикаятьләр күп. Юллар төзергә яратасыз. Әмма транспорт мәсьәләсе белән начар шөгыльләнәсез, – дип мөрәҗәгать итте ул транспорт һәм юл хуҗалыгы министрына. – Халык кырыгар минут автобус көтә, бернинди дә кысага сыймый бит бу. Министрлыкка гына түгел, муниципаль берәмлекләргә дә мөрәҗәгать итәм. Транспорт тармагы – иң зур кимчелегебез.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, автобуслар сатып алып кына мәсьәләне хәл итеп бетереп булмый. «Безнең бердәнбер юл – җәмәгать транспортын җайга салу. Юлдагы машиналар санын үзегез күреп торасыз. Бу кадәр транспортка купме юл салсак та, җитмәячәк», – диде Татарстан Рәисе.

Ул җирле юллар салу, булганын саклап тоту эшендә дә игътибарлырак булырга киңәш итте:

> 20–30 кеше яши торган авылга юл кирәк, ди. Шунда 70–100 миллион сумлык дүртенче яки бишенче категориягә караган юл салалар. Тыйнаграк булыйк! Вак таш түшәсәк тә, куркыныч түгел. Әйдәгез акыллырак эш итик. Ничек кенә булмасын, юлларны карап тору мәҗбүри.

Шелтәләп кенә калмады, чын күңелдән мактады да Татарстан Рәисе. Нишләтәсең, тик торган ат кына абынмый, диләр бит.

– Юл салу – авыр хезмәт. Сез ел әйләнәсе урамда эшлисез. Менә бу карлы буранда суыкта басып торып карагыз әле. Шуңа күрә хезмәтегезне хөрмәт итәбез һәм без сезгә бик рәхмәтле, – диде Рөстәм Миңнеханов юлчыларга.

Кабат министрга эндәшеп: «Бу кадәр эшне оештыру җиңелләрдән түгел. Халык бездән барысы да тиешле дәрәҗәдә булсын дип таләп итә. Безнең исә сездән башка сорар кешебез юк. Барыбызга бергә уңышлы эш телик», – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЧИТЛӘР ТҮГЕЛ

Татарстанның парламент делегациясе Беларусь Республикасына сәфәр кыла. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге делегация ике көн дәвамында рәсми очрашулар уздыра, алдынгы предприятиеләрне барып күрә.

Әлеге сәфәр Татарстан Дәүләт Советы белән Минск өлкәсе Депутатлар советы арасында хезмәттәшлек турында 2022 елның июлендә имзаланган килешү кысасында уза. Минскиның закон чыгару Җыены – Татарстан Дәүләт Советы хезмәттәшлек турында килешү имзалаган унберенче чит ил парламенты. Документ нигезендә, яклар парламент эшчәнлеге тәҗрибәсе белән уртаклашалар, үзара эшлекле элемтәләр урнаштыруга ярдәм итәләр. Килешүдә халыкны социаль яклау, фәнни-техник үсеш, гражданнарның иҗтимагый берләшмәләре арасында мәдәни элемтәләрне һәм аралашуларны киңәйтү, әйләнә-тирә мохитне саклау кебек юнәлешләрдә хезмәттәшлек итүгә өстенлек бирелгән.

10 ел дәвамында бу ил Татарстанның төп тышкы сәүдә партнерларының берсе санала. Казанда Беларусьның Россиядәге илчелегенең бүлеге эшли. 2004 елда Татарстан Хөкүмәте һәм Беларусь Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү имзаланган. Татарстанда тракторларның – 60, комбайннарның 40 проценты, Казан урамнарындагы һәр өченче трамвай, икенче автобус Беларусьта җитештерелгән. Татарстан делегациясе вәкилләре Минск өлкә башкарма комитеты рәисе Александр Турчин һәм Минск өлкәсе депутатлар Советы рәисе Наталья Якубицкая белән очрашуларда ике арадагы хезмәттәшлекне тагын да киңәйтү турында сөйләштеләр.

АЛТМЫШ БЕРЕНЧЕ СӘХИФӘ



Илдар Мөхәммәтҗанов

Иң көчлеләр кабат башкалага җыелды. 2–3 февральдә Казанда герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган көрәш турнирының 61 нчесе уза. Көрәшчеләр өчен иң дәрәҗәле турнирда быел нинди яңалыклар көтелә?

Бер баш өстен

Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турниры алдыннан матбугат очрашуы уздыру матур гадәткә әйләнде. Дөрес, сорауларга җавап алудан бигрәк, көрәшебезнең бүгенге хәле турында сөйләшүгә, киләчәк хакында киңәшләшүгә әверелә ул. Бу юлы да сүзне турнирның көрәшчеләр өчен әһәмияттеннән башладык. Көрәшчеләр дә, элек көрәшкәннәр дә, тамашачылар да көтеп ала торган турнир. Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов аны әнә шулай сыйфатлады.

– Бу турнир – күрешү, сөйләшү, хәл белешү өчен дә яхшы форсат. Ул электән көрәшчеләр арасында аерым урынны били. Җәлил турнирында җиңсәң, үзеңне башкалардан бер баш өстен итеп тоясың. Гәрчә аңардан тыш әле Татарстан, Россия, Дөнья беренчелеге булса да. Без көрәшкән вакытта да шулай иде ул. Турнирда җиңеп, үзеңне «Ватаным Татарстан» газетасы битләрендә табу үзе бер рәхәт, күңелле вакыйга иде. Ул газеталар, инде саргайсалар да, сандык төпләрендә саклана, – дип сөйләде Хәлил Шәйхетдинов, хатирәләргә бирелеп.

Газетабыз гамәлгә куйган турнирда 10 мәртәбә җиңүче булып, күпләрне таң калдырган Раил Нургалиев, матбугат очрашуында Муса Җәлил шигырен сөйләп, тагын бер кат шаккатырды.

– Бу турнирның дәрәҗәсе турында кечкенә чактан ук ишетеп үстек. Баш миенә сеңгән ул. Монда әзерлексез көрәшеп булмаганны да яхшы беләм, – диде ул турнир турында.

Бәйрәм бүген!

Дөрес, бүген көрәшчеләрне исем һәм дәрәҗә генә түгел, башкасы да кызыксындыра. Әйтик, быелгы турнирда акчалата бирелә торган приз күләменең артуы күпләр өчен яхшы яңалык булыр.

Быел I урын алган көрәшчеләргә – 100 мең сум; II урынга – 70 мең сум; III урынга 50 мең сум күләмендә акчалата приз биреләчәк.

Шулай ук быел көрәш сезоны нәтиҗәләре буенча иң көчле командаларга да саллы акчалата бүләкләр биреләчәк. Әле тагын елның иң оста көрәшчесе, иң яхшы тренерлар, журналистлар да бүләкләнәчәк. Чын мәгънәсендә көрәш бәйрәме!

– Муса Җәлил истәлегенә уза торган турнирның аерым бер үзенчәлеге бар. Без бу ярышта узган көрәш сезонына йомгак ясыйбыз, иң көчле командаларны бүләклибез. Алар инде билгеле. Быел беренче бишлеккә Әлмәт, Чаллы, Арча, Кукмара, Балтач командалары керде. Шулай ук яхшы күрсәткечләргә ирешкән Азнакай, Чистай, Лаеш командаларын да билгеләп узачакбыз. I урын алган командага – 500 мең сум, II урынга – 400 мең сум, III урынга – 300 мең, IV һәм V урыннарга – 250шәр мең, калган өч командага 100әр мең сум күләмендә акчалата премия биреләчәк, – дип сөйләде бу хакта Татарстан Көрәш федерациясенең башкарма директоры Марсель Таһиров.

Быелгы турнирда да батырлар 11 категориядә ачыкланачак. Авырлыгы 115 килодан артмаган егетләр өчен аерым категорияне узган ел керттеләр.

Рух

Безнең редакция өчен әлеге турнир – спорт бәйрәме генә түгел. Ул – рухи бәйрәм дә. Быел да без аның эчтәлегенә аерым игътибар бирдек. Бу хакта тулырак газетабызның баш мөхәррире Гөлнара Сабирова сөйләде.

– Татарстанның Көрәш федерациясе һәм Татарстан Спорт министрлыгының ярдәме булмаса, әлеге турнир бүгенгә кадәр, бәлки, килеп тә җитә алмас иде. Елдагыча, безнең редакция аның рухи эчтәлеге өчен җавап бирә. Быел без илдәге вакыйгаларны читләтеп уза алмыйбыз. Көрәшчеләр арасында махсус хәрби операциядә илебезне яклаучылар шактый. Безнең үзе дә батыр булган Муса Җәлил истәлегенә уза торган турнирда бүгенге батырларны күрсәтәсебез килә. Ягъни быелгы ачылыш һәм, гомумән, турнир батырлык, ныклык, Ватанны ярату, көрәшне ярату кебек төшенчәләргә бай булачак, – дип сөйләде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Язучы сүзе

Йөз аклыгы

Бик кирәкле, эзләп кенә табып була торган нәрсә турында «юлга чыгарып куймаганнар бит аны» дип әйтә торган гадәт бар. Кызыклы күренешләргә бу кагылмый бугай. Чөнки аларның барысын да диярлек юлга чыгарып куйганнар, бары тик вакытында күреп калырга гына кирәк. Кайберләре хәтта күзсез дә күрерлек дәрәҗәдә.

Бер абзый җиңел машина белән Илештән Казанга килгәндә авыл башында торган карчыкны күреп туктый. Утырта. Әби машинага кереп утыру белән:

– Балакаем, Чаллыга җиткәч, әйтерсең, – дип кисәтә. – Үземенң күзем дә күрми, һушым да юк, йоклап китүем дә бар. Чаллыга җиткәч: «Әби, Чаллыга җиттек!» – дип кычкырырсың.

– Ярый, апа, – ди рульдәге абзый, – аңладым барысын да. Чаллыга җитү белән уятырмын. Рәхәтләнеп йоклап бар, ял ит.

Илештән Чаллыга бара торган юл үзенчәлеклерәк ул. Үзе тар, үзендә хәрәкәт күп. Кайчагында мәңге яшәр өчен килгән кебек тоелучы кешеләр очрый да алар артыннан акрын гына барырга туры килә. Узып та китәлмисең, артка да калып булмый. Алар әле вакыты-вакыты белән бик күбәеп тә китә, шуларның багажнигына карап бара торгач, үзеңне чиксез мәңгелек буйлап хәрәкәт иткәндәй тоя башлыйсың. Моның ахыры да, чиге-чамасы да булмас сыман була.

Абзый да шулайрак итеп баргандыр инде. Өстәвенә, вак-төяк мәшәкатьләре булып, телефоннан да шалтыратканап торганнардыр. Анысы да һушны алырга бер сәбәп бит инде. Ничек кенә булмасын, онытканбу. Әби йокысыннан уянып:

– Балакаем, Чаллыга күп калдымы әле? – дип сөрәнләгәч кенә исенә төшкән.

Нишлисең инде хәзер? Мамадышка җитеп киләләр, өлкән яшьтәге карчыкны шушында төшереп калдырып булмый. Чаллы – Мамадыш арасы бик якын да түгел бит әле ул. Дөресен әйтсәң дә кыен, шуны да исендә тота алмаган, бигрәк сантый адәм икән, дип уйларга мөмкин. Үзе гаепле бит инде, берни дә кылып булмый.

– Озакламый килеп җитәбез, апа, бер дә борчылма, үзем әйтермен, – дип кире борылган.

Шулай дигәч, әби бик мәшәкатьләп тормаган инде, тынычланып, тагын күзләрен йомган. Матур гына итеп гырлап та җибәргән. Абзый музыка кушып, үзе дә шундагы җырларга үз сүзләре белән кушылып җырлап барган: «Мәңге дә онытмам Яр Чаллы каласын, онытмам әбинең Чаллыда каласын...»

Шулай дип җырласа да, абзый бу четерекле хәлдән шулай сиздерми генә котыла алуы өчен сөенгән инде. Башыңны эшләтсәң, теләсә нинди авыр хәлдән җиңел чыгып була икән. Аз гына мәшәкате бар, әлбәттә. Ләкин йөзең якты. Иң мөһиме шунысы бит инде аның. Нәрсә эшләсәң дә, хәтта ялгышлык кылсаң да, йөзең кызарырлык булмасын. Хатаңны үз вакытында төзәтә белү ул хаталанмауга тиң. Ни генә кылсаң да, иң мөһиме – йөз аклыгы.

Чаллыга килеп җиткәннәр хәзер. Абзый җайлап килеп туктаган инде. Һәм бурычын намус белән үтәгән лаеклы кеше кыяфәтендә гөрләтеп сөрән салган:

– Апа, Чаллыга килеп җиттек!

– Әй, балакаем, рәхмәт инде уятуыңа, – дип сөйләнә-сөйләнә әби сумкасында актарынырга тотынган. – Ходай сиңа хәерле гомер бирсен берүк. Күңел тынычлыгы белән куанычлы тормышта гомер итәргә язсын...

– Кайдарак төшеп каласыз соң? Берәрсе килеп аламы? – дип сораган әбинең теләкләренә күңеле булган абзый. – Кемгә барасыз соң, апа?

– Юк, балакаем, монда беркем дә килеп алмый. Казанга кадәр барам әле мин, – дип сумкасыннан нәрсәдер тартып чыгарган әби. – Кызым, Чаллыга җиткәч, даруыңны эчәргә онытма, шоферга әйтеп куй, дигән иде...

Моны ишеткәч, теге абзый килеп туктаган җирендә озак кына һушын җыя алмыйча утырган. Тынычланган инде соңыннан, барысын да аркылыга-буйга уйлап карагач. Чынлап та шулай бит инде ул. Һәрвакыт шулай. Шулай булырга тиеш.

Йөз аклыгын сакларга теләсәң, юлың уравырак була.

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Яшен суксын...

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бу язганнарыма, бәлки, бөтенләй ышанмассыз. Чөнки алар бернинди законнарга да сыймый кебек. Танышым сөйләгәндә: «Ай, шыттыра бу!» – дип баш чайкап утырдым.

Танышымның да, аның сабакташ кызының да исемен әйтмим, чөнки сөйлисе сүз күпмедер дәрәҗәдә әхлак мәсьәләләренә дә кагыла. Шуңа күрә танышымны – Гали, кызны Галиябану дип атыйк. Гали сөйләвенчә, Галиябану иптәш кызларыннан үтә дә кыргыйлыгы белән аерылып тора. Егетләргә билен, кулын тоттыру түгел, кем әйтмешли, бер чакрымга да якын җибәрми. Классташлары үзара: «Болай барса, Галиябану гомер буе ир чырае күрмәячәк», – дип сөйләшәләр. Кыз мәктәпне тәмамлагач та үзгәрми.

Җәйнең матур гына көннәренең берсендә авыл урамында шарсыман яшен пәйда була. Гали әйтүенчә, көн дә аяз булган, утлы шарның каян килеп чыкканын берәү дә күрмәгән. Ә аның нәкъ менә Галиябануларга таба баруын, капка төбендә басып торган кызга килеп бәрелүен күрше-күлән күреп торган. Шар юкка чыккач, җирдә яткан Галиябану янына йөгереп килгәннәр. Кыз бөтенләй кымшанмаса да, исән була. Мин Галидән түземсезләнеп: «Галиябану терелдеме соң?» – дип сорыйм. «Еще как!» – ди Гали, урысчалатып. Иң кызыгы: бөтенләй икенче кешегә әйләнгән Галиябану. Бер егеткә кияүгә чыккан, тагын берсе белән чуалган. Чуалу гына түгел, ярты ай – законный язылышкан ире йортында, ярты ай теге егет йортында яши башлаган. Безнең авылныкылар әйтмешли, «йөргән нәрсәсе»ннән бала да тапкан. Иң кызыгы: әлеге ике йорт арасында бернинди ызгыш-талаш чыкмаган.

Мондый тормыш озакка бара алмый, әлбәттә. Галиябану йөргән егете һәм баласы белән чит шәһәргә китәләр. Шул ук вакытта, бәйрәмнәргә авылга кайткач, Галиябану беренче иренең дә хәлен белеп чыкмый калмый, ди. Мондый «сәер мәхәббәт» турында бөтен ваклыкларын әйтеп яза алмыйм, чөнки кем турында сүз барганын чамаларга мөмкиннәр. Димәк, язмамның геройларын рәнҗетүем бар.

Миңа йомыкый Галиябануның кисәк кенә үзгәреп китүе гаҗәп тоелды. Өйгә кайткач, шарсыман яшен турында мәгълүмат җыя башладым. Шарсыман яшенне тикшерү белән шөгыльләнгән белгечләрнең фикерләре шактый ук төрле булып чыкты. Дөрес, берсе безнең очракка шактый ук туры килә. Мәсәлән, һәр биш очракның берсендә шарсыман яшенне аяз көнне күргәннәр. Ул җир астыннан килеп чыгып, төрле төсләргә кереп балкырга, пыяла аша үтеп чыгарга, кешене гипнозларга да мөмкин икән. Шарсыман яшенне беренче мәртәбә 1638 елда Англиядә күргәннәр. Шуннан соң ул инде меңнәрчә мәртәбә күзәтелгән, тик бу могҗизаның нәрсә икәнен бүгенгә хәтле төгәл генә аңлатып бирүче юк. Галиләр авылы кешеләре дә: «Әллә кайдан гына килеп чыкты, Галиябануны бәреп екты да җир астына кереп югалды...» – кебек сүзләр белән генә чикләнә.

Мин дә аптыраштa. Дөрес, әлеге могҗизаның бик борынгы икәнен чамалыйм. Мәсәлән, без яшь чакта: «Аяз көнне яшен суксын егет сөймәгәннәрен...» – дип җырлап урам әйләнә идек. Безнең кебек асыл егетләргә битараф булган кызлар өе турыннан узганда тәмам ертылганчы кычкырып җырлый идек. Бу җырны безнең әтиләр дә, бабайлар, бабайларның бабайлары да җырлагандыр, бәлки. Чөнки халык җырларына төгәл генә яшь биреп булмый бит ул.

Тагын нәрсә әйтим инде? Кичә генә Гали шалтыратты әле, ял көннәренә Галиябану авылга кайтып киткән. Их, үзен күреп бер сөйләшәсе иде.

ЧАТНАУ,

ЯКИ ЯҢА КОНФЕДЕРАЦИЯ МӘЙДАНГА КИЛГӘНДӘ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

vk.com

Соңгы атналарда Җир шарында хакимлек итүче глобаль системаның гадәттән тыш көчле чайкалуы вакыйгаларны азмы-күпме күзәтеп баручы һәркемгә ачык күренә. Игътибар Якын Көнчыгышка һәм... Америкага юнәлгән. Соңгы атнада бу ике төбәктә башларны әйләндерерлек вакыйгалар давылы булып узды. Глобаль капитализмның нигезе һәм терәге булган АКШ дәүләте төптән чатный башлады. Шундый тәүлек булды: океан артында менә-менә гражданнар сугышы башланмагае дигән шик уянды.

Без, СССР таркалуының шаһитлары булган буын, җимерелүнең билгеләрен яхшы хәтерлибез. Беренче һәм соңгы социалистик держава үзенең иярчен-сателлитлары булган куәтле хәрби һәм икътисадый потенциалга ия дәүләт булды һәм аның җимерелүен күз алдына китерү дә кыен иде. Әмма бармак белән санаулы еллар эчендә анда икътисадый хәл гадәттән тыш начарайды һәм читтәге төбәкләрдә үзәктән качу көчләре активлашты. Балтыйк буе республикаларына, Бакуга, Тбилисига танклар һәм гаскәрләр кертеп, кан коюю бәрабәренә илне саклап калырга тырышу нәтиҗә бирмәде. Шуңа охшаш процесслар бүгенге Америкада бара һәм тизләнә. Ил һаман да гадәттән тыш куәтле держава булып калуын дәвам итә әлегә, билгеле, әмма нигезендә чатнау билгеләре көннән-көн ешрак шәйләнә. Социализмның нигезе гадәттән тыш планлаштыру һәм үзәкләштерүгә корылган иде, аны шул җимерде дә. Глобаль капитализм тәгълиматы нигезендә процент капиталы һәм либеральлек ята. Процентлы әҗәтләр ярдәмендә кулында бернинди байлыгы булмаган һәркем бик җиңел генә мультимиллионерга һәм миллиардерга әйләнә ала дип санала. Уңышлы инвестиция проекты гына тап, банклар аны финанслаячак һәм син санаулы еллар эчендә бик бай кешегә әвереләчәксең.

Бераздан эш хәтта шуңа барып җитте: проектларның да кирәге калмады. Уңышлы биржа операциясе сине күз ачып йомганчы бай итә ала башлады. Әйтик, кайчандыр бер ипи телеме бәясе торган биткоин 60 мең долларга җитте. Вакытында йөз ипи телеме бәясендәге капиталны криптовалютага инвестицияләсәң, син бүген кыл кыймылдатмыйча да миллионер булыр идең. Мавыктыргычмы? Мавыктыргыч. Әмма математика каршы килә бу операцияләргә. Криптобиржалар җимерелә, фонд базарлары ишелеп төшә, кичәге миллиардерлар бүген ыштансыз калалар, чөнки 9 нчы класс баласы белгән геометрик прогрессия әйтә: процентлар өстәп барсаң, акчаны матди байлыклар белән тәэмин итү өчен Җир шарындагы мал җитмәячәк. Ни өчен замана капитализмының глобаль дигән эпитет алуын шуннан аңлыйсыздыр инде. Процент капиталына бер ил чиге генә тар, бөтен планетаны иңләү таләп ителә. Бераздан планета да кечкенә була башлый. Башка планеталар юк бит инде капиталга хезмәт итә торган. Шул сәбәпле глобальлек дигән тәртәне кире борырга туры килә. Без хәзер шул этапта. АКШ үзе түләп бетерә алмаслык бурычлар җыйды. Кытай да шулай ук. Европа һәм Япония дә шул хәлдә. Үсеп килүче илләр болай да бөлгенлектә инде. Алар үзләрен талаучылар кемнәр икәнен аңлап баш күтәрә башлады.

Boeing корпорациясе җитәкчелеге үткән атнада АКШ регуляторы (FAA) карарыннан зарланды: җитештерүне киңәйтергә рөхсәт бирми, ди. Регуляторда, күрәсең, бик яхшы аңлыйлар: киңәю өчен корпорация кредитлар алачак, ә менә җитештергәнне сатуы икеле. Шуңа күрә Портлендтан күтәрелеп киткәндә бер Boeing 737 MAX 9 самолетының ишеге төшеп калуны сылтау итеп тыю кертелде. Икътисадны ирексездән кысарга туры килә, процент капиталы исә андый кысылу-чикләүләрне яратмый, чөнки банк катастрофасына китерәчәк. Чыгып булмый торган проблемалар чытырманлыгы арасында калганны һәркем аңлый һәм вазгыятьтән файдаланучылар пәйда була. Үзәктән качучы көчләр мәйданга килә. Батып баручы корабны ташлаучы күселәр кебек алар да үз-үзләрен саклау инстинкты уяна. АКШ корабыннан беренче булып Техас штаты аерылырга тиеш. Ул – иң бай штат. Аның эчке тулай продукты 1,8 триллион долларга тигез, ягъни Россия, Көньяк Корея, Бразилия кебек илләрнекеннән зуррак. Җан башына бүлгәч, 78 мең доллар чыга. Чагыштырыгыз: Россиядә һәм Кытайда бу күрсәткеч 12 мең долларга тигез.

Үткән атнада Техас губернаторы Мексика белән чикне федераль чик сакчылары кулыннан тартып алып, штатның Милли гвардиясе кулына бирде. Мексикадан АКШка бик күп легаль булмаган мигрантлар агыла. Башында Байден торган демократлар моңа каршы берни дә эшләми диярлек. Трамп, мәсәлән, чикне япкан, миграцияне туктаткан иде. Игътибар итик: АКШта штатларның үз Милли гвардияләре бар һәм ил Конституциясе аерым шартларда аларны кулланырга рөхсәт итә. Техас, шуңа аркаланып, федераль үзәккә каршы чыкты. Вашингтонга бу ошамады, билгеле, фетнәче төбәккә киртәләргә керү өчен бер тәүлек вакыт бирде. Шактый киеренке вазгыять туды. Штат буйсынмаса, Үзәк үз сүзеннән кайтмаса, гражданнар сугышы башлану куркынычы бар иде. Техасны тагын 25 штатның губернаторы яклады. Хәтта үз милли гвардияләрен аңа ярдәмгә җибәрергә әзер торучылар да җитәрлек иде. Аларны кызыл штатлар дип атыйлар. Картага күз салсак, кызыл штатлар АКШны урталай бүлә. 1861 елда АКШта моңа охшаган вазгыять булган инде. Ул чакта җиде генә штат аерылып чыгып, конфедерация төзиләр һәм бу канкойгыч гражданнар сугышына китерә. Скарлет турындагы романны укучылар яисә киносын караучылар тарихтагы ул вакыйгаларны күз алдына китерә ала. Яңа конфедерация 26 штаттан тора. Сугыш башласа, Вашингтонның җиңүгә шанслары юк диярлек. Шуңа күрә Байден администрациясе ультиматум срогы чыккач, берни дә эшләмәде. Хәзер кызыл штатларның прокурорлары Вашингтонга закон өйрәтә, ә Техас прокуроры Кен Пэкстон Байден администрациясен җинаятьчел картельләр белән хезмәттәшлектә гаепли. Техаста юләрләр утырмый, билгеле. Алар хәзерге вазгыятьтә илне таркату куркыныч булуын аңлыйлар. Әмма Байден Горбачев костюмын киде инде. Вакыйгаларның үсеш мантыйгы исә АКШның глобаль держава буларак мәйданнан китүен таләп итә. Бу вазгыять ничә ел дәвам итәр, без белмибез, әмма хәзер штатлар Вашингтонга буйсынмый калырга өйрәнде инде.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

АКЫЛ САТУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Бирюса» да калышмый

Җырлы гаилә Рамилә һәм Рамил Хәйретдиновлар узган ел яңа фатирга күченгән.

– Моңа кадәр яшәгән фатирны ничек бар, шулай калдырдык. Шуңа күрә яңа нигезгә көнкүреш техникасын өр-яңадан сатып алырга туры килде, – ди Рамилә Хәйретдинова. – Хәзер кибетләрдә безгә таныш булган брендлар юк. Яңалары арасында сайланырга да туры килде. Суыткычыбыз – Кытайныкы, электр плитәсе белән мич – Белоруссиянеке. Робот-пылесос та Кытайдан кайтартылган. Көнкүреш техникасын сайлаганда, иң элек сатып алучылар интернетта калдырган бәяләмәләргә игътибар иттек. Бу эш белән күбрәк Рамил шөгыльләнде. Өйдәге яңа техниканың моңарчы без белмәгән, күрмәгән өстенлекле яклары яки, киресенчә, кимчелекләре бар дип әйтә алмыйм. Бәясенә күрә шул ук стандарт буенча җитештерелгәннәр инде алар. Әнә кер юу машинасы бик яхшы агарта. Иң мөһиме шул бит. Без барысыннан да канәгать. Эшләсеннәр генә.

Росстат мәгълүматларына караганда, былтыр Россиядә 8,7 миллион телевизор, 3,5 миллион суыткыч сатылган. Һәр ике очракта да Кытайның «Haier» техникасын күбрәк алганнар. Беренче бишлеккә безнең илдә җитештерелгән «Бирюса» бренды да эләккән.

Һиндстанда эшләнгән

Башкаладагы көнкүреш техникасы сатучы кибетләрнең берсендә сату-алулар бүлеге җитәкчесе Артур Захаров әйтүенчә, Европа брендлары илдән киткәч, кибет киштәләрендә Кытай, Белоруссия, Төркия кебек безгә дустанә мөнәсәбәттәге илләрдән кайткан кер юу машинасы, тузан суырткычлар саны бермә-бер артты.

– Хәтерләсәгез, узган ел башында көнкүреш техникасы кибетләре бушап калды. Безгә ел уртасында күпләп Кытай, Төркия техникасы кайта башлады. Кибетләр кабат җанланды. Бүген Һиндстаннан кайтартылган чәйнек-үтүкләр дә бар хәтта. Яңа брендларның сыйфатына килгәндә, алар начар, дип әйтмәс идем. Бер генә күрсәткеч: кибеттәге брак саны алдагы еллар дәрәҗәсендә калды, – ди ул. – Европа илләрендә җитештерелгән дигәч тә, алар бер дә ватылмыйча хезмәт итте дип уйлыйсызмы әллә? Юк. Сатып алучыларда Европа товарларына таләпләр зуррак иде, аерма шунда гына.

Кибетләрдә сайлау мөмкинлеге зур, ди Артур Захаров.

– Таныш брендларны күбрәк сорыйлар, әлбәттә. Тик шунысы да бар: «Samsung» дип язылган шул ук телевизор, мәсәлән, кытайлар тарафыннан җитештерелгән булырга мөмкин. Автомобиль базарындагы кебек үк, алар бездән киткән брендларның заводларын сатып алды һәм үз эшен шул технологияләр ярдәмендә дәвам иттерде. Бүген «LG»ның да Кытай телендә язылган «туган»ы бар. Бу исә сыйфатка берничек тә зыян салмый дип саныйм. Параллель импорт буенча Үзбәкстан, Казахстан кебек илләр аша кайтартылучы техника да җитәрлек. Кимчелекле яклары бар, әлбәттә. Мәсәлән, Үзбәкстанда җыелган шул ук «Samsung» телевизорының тышкы ягында, мәсәлән, җилем катып калган яки бармак эзләре булырга ихтимал. Шуңа күрә параллель импорттан баш тартучылар да бар, – ди бүлек җитәкчесе.

Гомумән дә, бүгенге шартларда товарның кайсы илдә җитештерелүе хәлиткеч урын алып тормый, дигән фикердә ул.

– Хәзер «акыллы» техникага өстенлек бирүчеләр күп. Ә эштән кайтырга чыкканда кабызып куя торган кер юу машиналары, суны билгеле бер температурада тотучы чәйнекләр белән иң беренче чиратта Кытай шаккатыра. Ватылган очракта, төзәтүгә килгәндә, бернинди кыенлык та юк. Товар сатучы аша барлык мәсьәләләрне хәл итеп була. Гарантия бар бит. Дөрес, хәзер күпчелек җитештерүчеләргә элеккеге кебек турыдан-туры чыгып булмый. Чөнки яңа кайта башлаган брендларның әлегә сервис үзәкләре юк. Гарантия буенча техникага ремонт ясаучыны чакырту өчен иң элек кибеткә шалтыратырга кирәк, – дип аңлатты Артур Захаров.

Үзе юа, үзе үтүкли

Көнкүреш техникасы кибетләрендәге вазгыятьне белергә теләп, «ВТ» хәбәрчесе дә «кер юу машинасы эзләп» кибеткә китте. Сатучы-консультант килгәнче, өч рәт булып тезелгән кер юу машиналарының исемнәрен дә санадык, бер кибеттә унөч төрле бренд тәкъдим ителгән иде.

– Өйдә әйбәт ярдәмче кирәк икән, «Haier» яки «Midea»ны (икесе дә Кытайда җитештерелә. – **Ред.**) сайларга тәкъдим итәм, – ди үзен Марат дип таныштырган сатучы, 45 мең сумлык кер юу машиналарына төртеп күрсәтеп. – Бу бәягә «Samsung» та бар, әлбәттә. Ул параллель импорт буенча Үзбәкстаннан кайткан. Тик Кытайда җитештерелгәннәре күпкә заманчарак. Параллель импорт юлы белән чит илләр аша товар алып кайту кыйммәткә төшә. Шуңа күрә безгә иске модельләрне җибәрәләр. Әнә «Haier» керне пар белән дә юа, барабанны да үзе чистарта. Өстәвенә ул үзебездә – Чаллыда чыга. Күпчелек техникага бер ел гарантия бирелә. Аны, өстәмә түләп, озайта аласыз.

Хәзер кер юу машинасы белән бергә кер киптерү машинасы сатып алучылар да күп, дип чит ил техникасын мактавын дәвам итте Марат. Анысы уртача 60–70 мең сум тора. «Аннары урын-җир әйберләрен, өйдә кия торган киемнәрне үтүкләп тә торасы булмаячак. Керне бер машинадан алып икенчесенә атасыз да бетте-китте», – ди сатучы. Ике төр техниканы бергә алган очракта кер юу машинасына 15 мең сум ташлама да бар икән. Кесә генә чыдасын.

ТЕХНИКА САТЫП АЛЫРГА ҖЫЕНУЧЫЛАРГА 5 КИҢӘШ

➤Кибет киштәсендәге яңа исем-атамалардан башың әйләнерлек. Шуңа күрә беренче күргән көнкүреш техникасын сатып алырга ашыкмагыз. Иң элек үзеңә ошаган кер юу машинасы яки суыткыч турында интернетта сатып алучылар калдырган бәяләмәләрне укып карагыз.

➤Бүген кибетләрдә параллель импорт буенча кайткан көнкүреш техникасы да җитәрлек. Әандыйларга җитештерүчедән гарантия каралмаган, кибет кенә үз гарантиясен бирергә мөмкин. Шуңа күрә бу сорауны ачыклап бетерегез. Сервис хезмәте кайда урнашканлыгын белеп тору да артык булмас.

➤Кибет киштәсендә икән, димәк, ышанычлы дип фикер йөртергә ашыкмагыз. Тузан суырткыч яки чәйнек сатып алганчы, электр җиһазының сертификатын сорагыз.

➤Бүген «акыллы» көнкүреш техникасының ниндие генә юк. Тик шунысы да бар: көнкүреш техникасы «акыллырак» булган саен, кыйммәтрәк. Үзегезгә кирәклесен генә сайларга тырышыгыз. Мәсәлән, суыткычлар арасында ризык бетеп килү турында «хәбәр бирә» торганы да бар. Әгәр болай да көн саен азык-төлек кибетенә йөрисез икән, ни өчен артык түләргә?

➤Кибет киштәсенә куелган көнкүреш техникасын сатып алмагыз. Бүген товар кайтартуга бәйле кыенлыклар булгач, сатучылар еш кына: «Бу үтүк бер генә данәдә кайтты», – дип хәйләләргә ярата. Ышанмагыз! Киштәдәге товар ул ремонт ясалган фен яки микродулкынлы мич булырга ихтимал.

«СОРАУ КИМЕМӘЯЧӘК»

Татарстан Иҗтимагый палатасының Финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәеновтан көнкүреш техникасы базарына бәйле мәсьәләгә ачыклык кертүен сорадык.

:: Халык кибеттә йөри икән, димәк, матди хәле әйбәтләнгәнме?

– Үзәк банк кушуы буенча, «Иҗтимагый фикер» фонды ай саен халык арасында фаразланган инфляция күрсәткечен билгели. Узган елның гыйнварына алынган соңгы мәгълүматларга караганда, ул – 14,2 процент. Бу урында шунысын да искәртик: былтыр рәсми инфляция 7,6 процент тәшкил итте. Илдә яшәүчеләр арасында фаразланган инфляция нәрсә соң ул? Әлеге күрсәткеч, халык фикеренчә, алдагы 12 айда бәяләр күпмегә артырга мөмкин икәнен күрсәтә. Ә бәяләр рәсми саннарга караганда да тизрәк үсәргә мөмкин дип саныйлар икән, димәк, үзеннән-үзе товар сатып ала башлыйлар. Соңгы арада илдә яшәүчеләрнең зур көнкүреш техникасы, автомобиль ише кыйммәтле товарлар сатып алуга йөз тотуы нәкъ менә шуңа бәйле: быел бәяләр тагын да артырга мөмкин дип куркалар. Югыйсә бәяләр бүген дә арзан түгел.

:: Шушы көннәрдә генә бу елның икенче яртысында төп ставка төшәргә мөмкин, дигән фикер әйттеләр. Быел бәяләр дә азмы-күпме төшәргә җирлек бармы?

– Үзәк банкның акча – кредит сәясәтенең төп максаты еллык максатчан инфляцияне 4 процент дәрәҗәсендә саклап тотудан гыйбарәт. Бу инфляцияне таргетлаштыру дип атала. Ягъни әнә шул күрсәткечкә омтылалар. Әлеге максат быел да үзгәрмәде. Алга таба карар кабул иткәндә, Үзәк банк гамәлдәге һәм халык арасында фаразланган инфляция күрсәткечләрен, бигрәк тә икенчесен исәпкә алачак. Озын сүзнең кыскасы, Үзәк банк кабул иткән чаралар инфляция күрсәткече кимүгә китермәячәк икән, алга таба бәяләр төшәргә җирлек юк. Бәяләр гел үсә анысы. Иң мөһиме – аларның күпмегә артуында. Инде әйткәнебезчә, Үзәк банк өчен уңайлы инфляция күрсәткече ул – 4 процент. Җәйгә таба халык арасында фаразланган инфляция күрсәткече кимесә, төп ставканы төшерүләре дә бик мөмкин. Якын арада исә техникага, бигрәк тә чит илдән кертелгәненә, сорау кимемәячәк. Бу елның беренче чирегендә, көнкүреш техникасына сорау узган ел дәрәҗәсендә калачак, дип фаразлыйбыз. Ә менә елның икенче чирегә Үзәк банк кабул иткән чаралар ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын күрсәтәчәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

АҢЛАШ(МА)У

БИШМУНЧА АВЫЛЫ ХАЛКЫ ХУҖА КӨТӘ

Әлмәт районының Бишмунча авылы халкы: «Авылыбыз дүрт ай хуҗасыз, өч ел җыйган үзара салым акчасына да эшләр эшләнмәде», – дип мөрәҗәгать иткәч, юлга кузгалдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авыл халкы җирлек башлыгын үз кешеләре арасыннан сайлап куярга тели.

Үз кеше

Бишмунча халкы безне китапханә бинасында каршы алды. Борчыган төп сораулары – авылда берничә ай дәвамында җирлек башлыгы булмау. Моңа кадәр эшләгән җитәкче Ришат Фазлыев узган елның сентябрендә эштән киткән. Дөресрәге, аны Яңа Никольский җирлегенә башлык итеп куйганнар. Закон буенча, авыл җирлеге башлыгын бары тик депутатлар арасыннан гына сайлап алырга тиешләр. Тик әлегә кадәр җиде депутат арасында җирлек башлыгы булырга ризалык белдергән кеше табылмаган, күрәсең.

– Безгә, беренче чиратта, депутатлар белән җыелышып сөйләшергә кирәк. Әбу мәсьәлә белән авыл советы шөгыльләнергә тиеш. Безнең арада үзебез ышана, килешеп эшли һәм булдыра торган кеше бар. Ник аңа депутатлыкка тәкъдим булмаган? – ди җыелган халык.

«Ышанычлы кешебез» дигәннәре Рауль Дәүләтшин. 2004–2010 елларда шушында ук җирлек башлыгы булган, дәүләт эшендә эшләгән кеше. Әйтүләренчә, бик яхшы эшләгән. Депутатлар арасында теләк белдерүче кеше булмагач, авыл халкы җыйналып, аны кабаттан шушы эшкә алынырга үгетләгән. Башта карышса да, соңрак ризалык биргән Рауль абый. Тик каршылык бар: ул депутат түгел.

Җыелган кешеләр арасында әлеге вакытта авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Римма Хәлимуллина да бар иде. Әлеге сорауны аңа юллагач, ул: «Миңа бу турыда әйткән кеше юк иде әле. Теләгегез бар икән, район белән сөйләшергә кирәк булыр. Чишеп булмаслык хәл түгелдер», – дип җавап бирде.

Гадәттә, ел башында уза торган җыеннарда җирлек башлыклары хисап отчеты бирә. Димәк, башлык булмагач, әлегә җыен да узмаячак дигән сүз. Әхалык нәкъ менә Ришат Фазлыевның узган елның үзе эшләгән сигез ае өчен хисап тотуын көтә. Аларны да аңлап була: үзара салым акчасының нәтиҗәсен күрәселәре килә, юк икән, аңлатып, ачыктан-ачык сөйләп бирүләрен телиләр.

Каршылык

Ришат Фазлыев җирлек башлыгы булып 2011–2015 һәм 2019–2023 елларда эшләгән. Безнең аңлавыбызча, элеккеге башлык белән очрашуга килгән кешеләр арасында аңлашу, санлашу, уртак фикердә булу, хөрмәт җитеп бетмәгән. Алар әйтүе буенча, Фазлыев башлык булып торган вакытта күп эшләр игътибарсыз калган, Сабантуй уздырылмаган еллар да булган, бәйрәмнәрдә килеп котлау, халык белән аралашу булмаган. Аеруча борчыган төп мәсьәләләре: 2021–2023 елларда җыйган үзара салым акчасының «эшкә җигелмәве».

– Без моңа кадәр күпме акча җыелганлыгын да, казнада ничә сум акча барлыгын да белмибез, чөнки безнең алда хисап тоткан кеше юк. Без алга таба да акча җыярга каршы түгел, бары тик нәтиҗәсен генә күрәсебез килә, – диде Морат Мөбарәкшин.

Өч ел рәттән җыелып, дәүләттән артып кайткан акча су линиясен төзекләндерүгә тотылырга тиеш булган. Тик боз урынннан кузгалмаган. Халык элеккеге җирлек башлыгын, берни эшләмәде, дисә дә, Рауль Дәүләтшин алай ук кистереп әйтергә ашыкмады.

– Ришатны гел эшләмәде, дип әйтеп булмый. Аз-азлап булса да, юлын да карады, су линияләрен дә төзекләндерде, утларны да тәртипкә салды, – диде ул.

Эш эшләү генә җитми, аны күрсәтә белү, кайбер очракларда сабырлык, аңлашу, фикерләшү дә кирәк булган, күрәсең.

– Безгә үз кешебез кирәк. Авылны яратучы, аның киләчәгеннән чыннан да кайгыртучы, аңлаучы, санлаучы булсын ул, – дип үз сүзендә торды Илдар Лотфуллин.

Аның фикеренә Морат Мөбарәкшин да кушылды:

– Авылга төпле хуҗа кирәк! Түзәр чама калмагач, сезгә мөрәҗәгать иттек бит инде. Безнең халык тырыш, булдыклы, бердәм. Авылны таркатмыйча, матур итеп яшисебез килә.

Яңа башлык итеп сайланган очракта, Рауль Дәүләтшинга ярдәм итәргә әзер булуларына да кат-кат басым ясады алар. Шушы еллар эчендә эшлисе эшләр дә шактый җыелган: контейнерлар мәсьәләсен хәл итәргә, һәйкәлне яңартырга, зиратларны, юлларны карарга һәм кул җитмәгән башка эшләрне башкарып чыгарга кирәк. «Депутатлар составы көчле монда. Алар белән уртак тел тапкан очракта, эшләргә була дип уйлыйм», – дигән фикерен дә җиткерде Рауль Дәүләтшин.

Авыл халкы мәктәп мәсьәләсен дә күтәрде.

– Безнең башлангыч мәктәп Яңа Нәдер урта белем бирү мәктәбенең филиалы булып санала. Тик әти-әниләр балаларын үзебездә һәм Нәдер мәктәбендә укытмыйча, Түбән Мактама авылына йөртә. Бүген анда безнең авылның 27 баласы укый. Кемдер баласының башта ук шул мәктәпкәияләшүен тели, кемдер олы балалары белән бергә йөрсен ди, сер түгел, русча укып, БДИ бирергә әзерләнсен, диючеләр дә бар, – диде Лилия Купаева.

Кечкенә, сүнеп барган авыл да түгел югыйсә Бишмунча. 750 тирәсе кешесе, 290лап хуҗалыгы бар. Башлангыч мәктәбе, балалар бакчасы, клубы, китапханәсе, мәчете эшли. Мәдәният, спорт ягыннан да бик активлар. «Гөлкәйләр», «Мәдинәкәйләр» коллективлары, көрәшче егетләре белән данлыклы. Хезмәт яшендәгеләр нефть оешмаларына барып эшли.

> **Авылның шактые пенсия яшендә булса да, шушында төпләнеп калып, йортлар тергезгән яшьләре дә, көчле фермерлары да бар. Кыскасы, рәхәтләнеп, гөрләп яшәрлеге бар. Иң мөһиме: актив, авылның киләчәге өчен янып-көеп йөрүче халкы бар. Эшлисе килеп торган кешегә яшел ут кына кабызып, ярдәм итеп кенә җибәрәсе бит югыйсә.**

Таякның икенче башы

Римма Хәлимуллина очрашуыбыз ахырына кадәр утыра алмады. Шуңа күрә аның белән аерым сөйләштек. Озак еллар секретарь булып эшләгән ханымга ике авыл җирлеге башлыгы белән дә эшләргә туры килгән.

– Мин Рауль Ханифович белән дә, Ришат Газизянович белән дә әйбәт эшләдем. Берсен дә хурлап бер сүз әйтә алмыйм. Авыл өчен тырышып йөргән Ришат Газизяновичның да, берничә кешенең фикере белән генә, эшләгән эшләрен бетереп атасым килми. Мөмкинлеге булган эшләрне эшләде. Ул килгәндә урам баганаларындагы утлар буенча саллы гына бурычлар җыелган иде. Барысын да алыштырып, караңгы урамнарны да утлы итте. Килгән вакытларында ук Кама-Исмәгыйль авылы белән Бишмунча арасындагы, урам юлларын карады. 2022 елда су линияләрен карады, трактор кайтардык. Билгеле, бөтен эшләрне дә берьюлы берничек тә эшләп бетереп булмый. Ләкин ул алга карап, план белән эшләүче җитәкче булды, – диде ул.

Үзара салым акчасы мәсьәләсенә килгәндә, түбәндәге фикерен җиткерде:

– Су линиясе белән эшләгән вакытта подрядчы оешмаларга бик уңайсыз. Эшләгәннәре өчен акча калмый, диләр. Шуңа күрә алынырга теләмиләр. Бер ел эчендә 4 подрядчы оешма гына алышынды. Халыкның шуңа да ачуы чыкты. Узган елның көзендә эшкә бер оешма тотынды тотынуын, тик кышка калгач, туктадылар. Быел дәвам итәргә тиешләр. Әакча беркая да китмәде, счетта тора. Аларның берникадәренә торбалар, кирәкле эш җиһазлары алынды инде.

Ришат Фазлыевның үзенә дә чыктык. Үзара салым акчасы буенча ул да Римма Хәлимуллинаның сүзләрен кабатлады. Санап киткән эшләре дә шактый.

– Мин килгәндә башлыкның эш машинасы да юк иде. Аны өч елдан соң гына бирделәр. Багана утлары өчен 1,5 млн сум бурычлары бар иде. Анысын да ерып чыктым. 22 яктырткыч урынына бүген урамнарны 270 яктырткыч яктырта. Юллар, су линияләре каралды, трактор алдык, авыл урамнарын, чишмәләрне артык агачлардан чистарттык.

Эшләнгән эшләрнең күпчелеге иганәчеләр ярдәме белән эшләнде, – диде ул.

Ришат Фазлыев авылда яшәүчеләрнең кайберләре белән уртак тел таба алмавын да, үзара аңлашу булмавын да яшермәде.

– Авыл халкы минем белән идарә итәргә теләгән иде, ләкин мин баш бирмәдем. Шәһәр кешесе булуымны да яратмадылар. Шуңа күрә төрле урыннарга шикаятьләр язгалап тордылар. Ләкин килеп тикшергәч, эшемдә хилафлыклар юклыгын күрделәр, документлар тәртиптә. Хәзер инде мин ул эштән киттем, башка җирлекне җитәклим. Ни өчен әле мин алар алдында хисап тотарга тиеш? – диде ул.

Әлмәт районы башкарма комитетының җирле үзидарәләр белән эшләү бүлеге башлыгы Ирина Шаргина, яңа башлыкны билгеләп куяр өчен, депутатларның барысын бергә җыярга кирәклеген әйтте.

– Башлык алар арасыннан сайланып куелырга тиеш. Депутатларга үзара сөйләшеп җыелырга кирәк. Һаман да җыелыш юк икән, халык инициатива күрсәтергә мөмкин. Ләкин әлегә алардан андый теләк булмады, – диде ул. – Җирлек советы составында депутат җитмәгән очракта, халык аны җирле сайлау вакытында бары тик тавыш бирү юлы белән генә сайлый ала. Әлеге вакытта җиде депутат та – үз урынында, барлык сайлау округлары да тулы.

> Әгәр депутат булмаган кеше җирлек башлыгы булырга теләк белдерә икән, ул җирлек советына үзенең кандидатурасын тәкъдим итә. Депутатлар караганнан соң, аны җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары итеп билгеләүләр яки кире кагалар.

Җитәкче сүзләренчә, Ришат Фазлыев эш урыныннан киткән вакытта бер генә кеше дә бу мәсьәлә буенча аңлатма таләп итмәгән, шулай ук авылдагы хәлләргә канәгатьсезлек белдерүче дә булмаган.

– Ә бер ел эчендә файдаланылмаган үзара салым акчасы тулы күләмдә (ягъни халыкның җыйган акчасына бюджет кушкан сумма) җирлек бюджетында саклана. Узган еллардагы калган акча да билгеле бер статья нигезендә счетта ята, беркая да югалмый, – дип аңлатты Ирина Шаргина.

Акчаны саклау турында сорауны без Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенә дә җиткердек. Матбугат үзәгеннән исә мондый җавап алдык: «Халыкның үзара салым акчасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында авыл җирлекләре счетларында саклана. Министрлар Кабинеты карары нигезендә, узган елда файдаланылмыйча калган бюджетара трансфертлар ел узганнан соң, беренче 15 эш көне эчендә республика бюджетына кире кайтарыла.

Узган елда файдаланылмыйча калган бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында министрлык карар чыгарган очракта, файдаланылмыйча калган акча (калганнан артмаган күләмдә) агымдагы елда муниципаль район (шәһәр округы) бюджетына тиешле чыгымнарны финанслауга кире кайтарылырга мөмкин.

Файдаланылмыйча калган бюджетара трансфертлар республика бюджетына кучерелмәгән икән, бу акча министрлык билгеләгән тәртиптә Татарстан бюджетына кире кайтарылырга тиеш».

9 февральдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан ГАРИФУЛЛИНА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Нинди кагыйдәләр бар?

Кыш уртасында бакчадагы йортыбыз янды. Күршеләрнең балалары шашлык пешерергә килгән икән. Учакны безнең йортка якын урында якканнар. Саксызрак та кыланганнардыр инде. Шуңа кагылышлы нинди законнар, кагыйдәләр бар икән? Шул хакта языгыз әле. Тагын берничә айдан сезон да ачыла. Учак ягучылар, шашлык пешерергә теләүчеләр күп булыр. Уйлана торсыннар иде.

Галимҗан ХАТЫЙПОВ.
Казан

Гөлсинә Хәкимова, юрист-эксперт:
– Янгынга каршы көрәш кагыйдәләре 2024 елда тулысынча үз көченә керде. Чыннан да, бакчачыларның беренче көне шашлык әзерләүдән башланып китә. Форсаттан файдаланып, кисәтеп куябыз: мангал йорт-җирдән – 5 метр, ә коймa, беседка кебек корылмалардан 2 метр ераклыкта торырга тиеш. Үз биләмәңдә чүп-чар һәм чыбык-чабык яндыру да тиешле кагыйдәләргә нигезләнгән. Моның өчен корылмалардан – 50 метр, ылыслы агачлардан 100 метр ераклыкта металл савыт урнаштырырга кирәк.

Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен 5 меңнән алып 15 мең сумга кадәр штраф каралган. Күршеләргә зыян килгән очракта, штрафның күләме 40 меңнән алып 50 мең сумга кадәр. Өстәвенә күршеләргә килгән зыянны да капларга туры киләчәк.

Васыятьне кулдан язарга ярыймы?

Хәлем авыраеп киткәч, кулдан гына васыятьнамә язган идем. Күршем керде дә: «Хәзер кулдан язмыйлар инде, компьютерда бастырырга кирәк», – ди. Бу сүз дөресме икән? Миндә андый әйберләр юк бит. Кулдан гына яза алам. Авылда яшәгәч, нотариус янына да барып йөри алмыйм. Телефоннан шалтыратып сөйләшергә генә мөмкинлегем бар.

Таһирә ВӘЛИУЛЛИНА.
Яшел Үзән районы

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
– Чыннан да, күп вакытта кешенең нотариус янына барып, васыятен рәсмиләштерергә мөмкинлеге булмый. Васыятьнамәне кулдан язарга да, компьютерда бастырырга да ярый. Әмма нотариуста рәсмиләштерү мәҗбүри. Эксперт кешенең теләген белергә, бу эшнең кемнең дә булса басымы астында эшләнмәвенә инанырга тиеш.

Әмма, Таһирә апа язганча, кайбер очракларда кеше нотариуска мөрәҗәгать итә алмый. Бу очракта нотариусны башка вазыйфаи затлар алыштыра ала. Мәсәлән, васыятьнамә язучы хастаханәдә ятса, баш табибка яки аның урынбасарына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Судноларда бу рольне – капитан, хәрби частьларда – командир, экспедицияләрдә – җитәкче, иректән мәхрүм ителгән урыннарда төрмә яки колония начальнигы һ.б. үз өстенә ала. Кайбер торак пунктларда нотариуслар бөтенләй булмаска мөмкин. Мондый очракларда бу мәсьәләне җирле үзидарә органнарында эшләүче вазыйфаи затлар хәл итәргә тиеш. Васыятьнамә язучы документны вазыйфаи зат һәм шаһитлар алдында имзалый, соңгылары да, дөреслеген раслап, шунда ук кул куялар.

Җирне ничек рәсмиләштерергә?

Бер туганым йорт-җирен мирас итеп калдырган иде. Документта йорт урнашкан җир турында берни дә әйтелмәгән. Участокны рәсмиләштерергә кирәкме икән? Кирәк булса, эшне нидән башларга?

Гөлүсә СӘЙФИЕВА.
Минзәлә

Галина Галиуллина, Росреестрның Татарстан бүлеге матбугат җитәкчесе:
– Мираска бирү юлы белән генә түгел, башкача берәр милеккә ия булган очракта да корылмалар урнашкан җирне рәсмиләштерү кирәк һәм ул катлаулы эш түгел. Моның өчен түбәндәге документлар таләп ителә:

– җир участогының сезгә бирелүе турында җирле үзидарә органы чыгарган карар;

– җир участогына хокук турында дәүләт органы тарафыннан бирелгән акт;

– җирле үзидарә органы тарафыннан бирелгән хуҗалык кенәгәсеннән өземтә (җир участогы шәхси хуҗалык алып бару өчен тәгаенләнгән очракта);

– әгәр булса, җир участогына хокукларыгызны раслаучы башка документлар.

Югарыда күрсәтелгән документлар булмаса, кучемсез милек урнашкан җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итегез.

Документлар кулыгызда булса, милеккә хокукны теркәү өчен күпфункцияле үзәкнең теләсә кайсы офисына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Теркәү вакыты – 9 эш көне. Дәүләт пошлинасы күләме – 350 сум.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА
әзерләде

КЕМГӘ НӘРСӘ ТИЕШ?

Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге 2024 елда мөһим үзгәрешләр турында искә төшерә

✓Туендыручысын югалту сәбәпле пенсия, шулай ук ата-аналарының икесе дә билгеле булмаган балаларга социаль пенсия гариза тапшырмыйча гына билгеләнәчәк. Пенсия Россиядә яшәүчеләр турында мәгълүматларның федераль регистрыннан туендыручының үлеме турында мәгълүмат кергән көннән алып 5 эш көне эчендә билгеләнә.

✓2024 елның 1 гыйнварыннан эшләмәүче пенсионерларның иминият пенсияләре 7,5 процентка артты. Иминият пенсиясенең күләме – 8134,88 сум.

✓Пособиеләрнең яңа максималь суммалары билгеләнде. Тулы календарь ай өчен «больничный»ның максималь суммасы:

✓иминият стажы 8 ел һәм аннан да күбрәк булганда (уртача хезмәт хакының 100 проценты) – 122807,79 сум;

✓иминият стажы 5 елдан 8 елга кадәр булганда (уртача хезмәт хакының 80 проценты) – 98246,23 сум;

✓иминият стажы 5 елга кадәр булганда (уртача хезмәт хакының 60 проценты) – аена 73684,67 сум.

✓Эшләүче хатын-кызлар өчен йөклелек һәм бала табу буенча пособиенең максималь суммасы 565562,20 сумга җитә. Бала карау буенча айлык максималь пособие – 49123,12 сум.

✓Инвалид балаларны һәм инвалидларны тәрбияләүче затларга ун мең сум күләмендә ай саен түләнә торган пособие эшләмәүчеләргә генә түгел, ә тулы булмаган эш вакыты шартларында, шул исәптән өйдән торып эшләүче ата-аналарга (опекуннарга) да биреләчәк.

5 февраль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Халкым минем...» 12+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Дуслык илендә» 12+
17.45 «Таяну ноктасы» 16+
18.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Сибирь» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Җырлыйк әле!» 12+
01.45 «Таяну ноктасы» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ватандашлар» 16+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 15.25, 19.15 Новости
07.05, 19.20, 22.05, 00.45 Все на Матч!
10.05 «Лица страны» 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Еврофутбол. Обзор 6+
12.35, 04.05 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!»
14.25 «Сочи. 10 лет спустя» 12+
15.30 «Громко»
16.30 Футбол. Кубок равноправия. «Зенит» – «Аль-Духаиль»
19.55 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Зенит» – ЦСКА
21.35 «Что за спорт?» 12+
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Рома» – «Кальяри»
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Лёгкая атлетика. Международные соревнования «Русская зима» 6+
04.25 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Чеховские медведи» – «Машека» 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.55 «СПЕЦИАЛИСТ» 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 06.10 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.20 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.35 «Порча» 16+
12.55, 01.25 «Знахарка» 16+
13.30, 01.50 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ВЕРОНИКА» 16+
19.00 «ТЁМНОЕ ПРОШЛОЕ» 16+
02.45 «ПРО ВЕРУ» 16+
06.00 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «Забытые войны России» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 «Новости дня» 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.15 «ОЦЕОЛА» 12+
13.25, 03.40 «РОЗЫСКНИК» 16+
15.00 «Военные новости» 16+
18.00 «Два дела Феликса Дзержинского» 16+
18.50 «Спецрепортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «СЛУЧАЙ В ТАЙГЕ» 12+
02.50 «Нюрнберг» 16+

6 февраль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Татар халык җырлары» 0+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Татарлар» 12+
16.30 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Ихсан күңел» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Сочи. 10 лет спустя» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 15.25 Новости
07.05, 15.30, 18.45, 21.50, 01.00 Все на Матч!
10.05, 12.35, 04.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Профессиональный бокс. Феликс Тринидад против Фернандо Варгаса 16+
13.00 «Есть тема!»
16.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» – СКА
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» – «Автомобилист»
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/2 финала. «Мальорка» – «Реал Сосьедад»
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Лёгкая атлетика. Мировой тур в закрытых помещениях 6+
04.25 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Зенит» – ЦСКА 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.55 «СПЕЦИАЛИСТ» 16+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.25 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.50, 01.20 «Знахарка» 16+
13.25, 01.45 «Верну любимого» 16+
14.00, 02.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «ОТВЕРЖЕННАЯ» 16+
19.00 «СЛУЧАЙНЫЙ БРАК» 16+
02.40 «ПРО ВЕРУ» 16+
05.55 «6 кадров» 16+
06.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 «Новости дня» 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.10 «СЕВЕРИНО» 12+
12.35, 03.20 «Война в Корее» 16+
15.00 «Военные новости» 16+
18.00 «Два дела Феликса Дзержинского» 16+
18.50 «Спецрепортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «АЛЛЕГРО С ОГНЕМ» 12+
02.25 «Нюрнберг» 16+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРУ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

СУСАГАННЫ КӨТӘСЕ

Авырганда юынырга ярыймы? Чәч коелу ашказанына бәйле була аламы? Чиста су эчү мәҗбүриме? Сәламәтлеккә бәйле сораулар әледән-әле туып тора. Бүгенге сәхифәбезне әнә шуларга багышларга булдык.

Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб пульмонологы Рөстәм НАСРЕТДИНОВ җавап бирде.

:: Соңгы арада бик нык чәчем коела, тырнаклар сына. Бу ашказаны авырткангa күрә була аламы?

– Була ала. Әмма башта кан, сидек, гомуми кан анализы тапшырырга кирәк. Бу гемоглобинны тикшерү өчен кирәк. Ул түбәнәйгәндә, еш кына чәч коела башлый, тырнаклар сынучанга әйләнә. Калкансыман биз эшчәнлеген дә тикшертергә кирәк. Ул яктан бар да тәртиптә булса, дерматологка мөрәҗәгать итәсе булачак. Дерматолог чир тапмаса, гастроэнтерологка барыгыз. Организмга кирәкле бөтен микро- һәм макроэлементлар, витаминнар эчәклек аша сеңә. Аларның җитмәве шулай ук чәч, тырнаклар зәгыйфьләнүгә китерә.

:: Авырганда юынырга ярыймы?

– Күпләр, авырганда юынырга ярамый, аннан соң хәлең тагын да авыраячак, дип саный. Хәтта чәч юарга куркып торучылар да бар. Әмма бу курку урынсыз. Әгәр кешенең температурасы юк икән, тиз генә юынып чыгуның бер зыяны да юк. Авырганда кичке якта юыну хәерлерәк. Чыккач, яхшылап сөртенергә, үтәли җилдән сакланырга кирәк. Юынып чыккач, җылы киенеп, түренеп йокларга ятудан да яхшысы юк.

:: Ковид белән авырган идем. Борыным әле һаман ис сизми. Ни эшләргә икән?

– Ковидтан соң ис сизмәү – еш очрый торган күренеш. Авырып терелгәннән соң ис тоемлау акрынлап кире кайта ул. Әмма аны тизләтү өчен, өйдә көн саен гади генә күнегү дә ясарга мөмкин. Моның өчен дарчин, әфлисун яки лимон алырга кирәк. Аларны урталай кисеп, һәрберсен алмаш-тилмәш 15 секунд дәвамында иснәгез. Ашыкмыйча, акрынлап, аларның исен искә төшерергә тырышыгыз. Бу күнегүне көнгә берничә тапкыр кабатлагыз. Безнең баш мие шулай корылган: әйберне күрү, аңа кагылу белән аның исе дә күз алдына килеп баса. Бу күнегү дә шуңа нигезләнгән.

:: Тик торганда чиста су эчәргә ярат-мыйм. Дөресрәге, эчә алмыйм. Әмма табиб көненә ким дигәндә 2 литр чиста су эчәргә кушты. Үземне мәҗбүриләп, чиста су эчү дөрес булырмы?

– Шәхсән мин үзем көненә фәлән литр чиста су эчү мәҗбүри дигән сүзгә кискен каршы. Фәнни яктан беренди аңлатмасы булмаган кагыйдә бу. Уйдырма дисәк, дөресрәк тә булыр. 1945 елда Американың азык-төлек һәм туклану буенча комиссиясе зурларга

shutterstock.com

көненә якынча 2 литр су эчәргә кирәк дигән тәкъдим чыгара. Документта, бу ике литрга көн дәвамында ашаган-эчкән, сыеклык, ризыктагы су күләме дә кергәнлеге искәртелә. Ә бүген көненә шулардан тыш тагын өстәмә 2 литр су эчәргә кушалар. Чынлыкта чиста суны сусаган саен гына эчәргә кирәк. Бар да кешенең яшенә, гәүдә төзелешенә, нәрсә ашавына, метаболизмга бәйле.

:: «Пневмо 23» вакцинасы кемнәргә тиеш? Аны түләүсез ясатып буламы?

– Әлеге вакцина пневмония, отит, менингит кебек чирләр китереп чыгаручы пневмококка каршы ясала. Пневмонияне булдырмас өчен, аны биш елга бер тапкыр кадыйлар. Аны «Превенар 13» вакцинасы белән бергә ясату да яхшы. Прививкалар календаре буенча әлеге вакцина 2–3 айлык, 5–6 айлык, 1,5 яшьлек балаларга да билгеләнә. Шулай да «Пневмо 23» вакцинасы иң беренче чиратта хәвеф төркеменә кергән, 65 яшьтән өлкәнрәк, хроник үпкә авырулары, шикәр чире, йөрәк, аутоиммун авырулары булган, гемодиализдагы, яман шеш диагнозы куелган кешеләргә ясала. Әмма ул фәкать табиб белән киңәшеп кенә эшләнергә тиеш. Әлеге вакцинаны бушлай да ясатып була.

Кирәге чыгар

Бавыр нәрсә ярата?

Кышын бавырыбыз аеруча игътибарга мохтаҗ. Салкын көннәрдә артык тәмле, югары калорияле ризыклар ашарга яратуыбыз галәмәте бу. Бавырга ничек ярдәм итәргә? Укроп, петрушка, кинза, сельдерей, рәйхан һәм бөтнек кебек табигый антиоксидантлар бавырга организмны чистартырга булыша. Чөгендердәге клетчатка, фосфор, бакыр һәм В төркеме витаминнары токсиннарны чыгара һәм бавыр эшен җиңеләйтә. Кабак та – бавырның дусты. Ул тиз үзләштерелүе белән файдалы. Алма белән груша исә кан составын яхшырта. Әстерхан чикләвеге составындагы аргинин бавырдан аммиакны чыгара, ә омега-3 бавырны сәламәт хәлдә тота. Кузаклы культуралар тиз үзләштерелә торган аксымга бай. Алар тукымаларны, шул исәптән бавыр тукымаларын да яхшырта.

Имән бармак сызлатмый

Бармаклар әллә нигә сәләтле! Алар ярдәмендә хәтта организмдагы шактый авыруны да җиңеп була. Әйтик, ашказаны, эчәк авырулы кешеләргә – имән бармакка, теш сызлаганда, бу бармакның тырнак астындагы ноктага массаж ясарга кирәк. Урта бармак кан тамырларының көйле эшләве өчен җаваплы. Шуңа күрә кан басымы уйнаганда, нәкъ менә шушы бармакка массаж ясау хәерле. Үпкәдә тайпылышлар булганда, баш бармакны уарга киңәш ителә. Баш бармак тырнагының айга охшаган ак өлешенә басу ярдәмендә ютәлдән дә котылырга мөмкин. Исемсез бармакка ясалган массаж стресстан коткара, тынычландыра. Йөрәк һәм нечкә эчәк өчен җаваплы чәнти бармакны уып, эч кибүдән котылырга, йөрәк эшчәнлеген яхшыртырга мөмкин.

Үзем сынадым

Кабыгы булышты

Үзган ел кыш буе ютәлдән интектем. Танышым мандарин кабыкларыннан төнәтмә ясап карарга киңәш итте. Шуның файдасын күрдем бит. Ясау бик җиңел. 2–3 уртача зурлыктагы мандарин кабыгын ваклап, шуның өстенә бер стакан кайнар су коясы. Шуны ярты сәгать төнәткәч, сөзеп, һәр иртә ач карынга бер стакан күләмендә эчеп куярга кирәк. Бер атна дигәндә ютәлнең эзе дә калмады.

Сарманнан СӘРИЯ апагыз

Сорау – җавап

Ничек уздырырга?

Магнитлы давыллар вакытында бөтенләй сафтан чыгам. Андый көннәрне ничек җиңелрәк уздырырга икән?

Илсинә. Арча

Сорауга табиб-невролог Диләрә Шаһиева җавап бирә:

– Магнит давылы котырган көннәрдә физик күнегүләр ясаудан, спорт залына йөрүдән тыелып торыгыз. Ник дигәндә, физик күнегүләр башкарганда, кан агышы көчәя. Магнит давылы вакытында исә кан куерган була. Димәк, организмга икеләтә авырлык килә дигән сүз. Бу чорда күпләп яшелчә, җиләк-җимеш ашау, балык ризыклары, төрле ярмаларга өстенлек бирү хәерле. Үлән чәйләре эчү дә комачауламас. Мелисса, бөтнек, арыслан койрыгы (пустырник) үләннәреннән ясалган чәй аеруча яхшы тынычландыра. Вакытында йокларга ятып, вакытында торырга тырышыгыз.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

Укучы киңәше

Суганны капчыкта үстерәм

Суган кыягын тәрәзә төбендә үстерү өчен, целлофан капчыктан файдаланудан да яхшысы юктыр, мөгаен. Болай эшлим. Капчык төбенә бер катлам пычкы чүбе салам. Төбе тулганчы, башлы суганнарны тезәм. Шуннан капчыкка һава өреп тутырам да өстен скотч белән ябыштырып куям. Капчыкны караңгырак урынга урнаштырам. Суганнары тамырлана башлагач, тәрәзә төбенә күчерәм.

10–15 көннән соң суган кыяклары 20–25 сантиметрга үсеп, бушлыкны тутыра. Шуннан, капчыкны ачып, уңышны җыеп аласы гына кала.

Нурания ХӘСӘНОВА.
Буа шәһәре

Хуҗабикәгә

БӘРӘҢГЕ КЫЗДЫРУ СЕРЕ

Аны озынча итеп тураганнан соң, кайнап торган суга салып, 5 минут торырга кирәк. Шуннан, судан алып, тастымал белән бераз гына киптереп, майга салып кыздырырга. Алтынсу төскә керсен өчен, өстен капламаска. Ә инде изелмичә кызсын өчен, ахырдан гына тоз сибәргә!

«ИСЕМЛЕ» КАМЫР

Лимон яки башлы суган согы, яки бераз гына аш серкәсе кушылган сөт белән кәгазьгә язып, аны бераз гына ут өстендә тоткан очракта язуларның аермачык күренәчәген беләсезме икән? Бу ысулны камыр ризыгы пешергәндә хуҗабикәләр дә кулланa ала. Газ мичендә куяр алдыннан күмәч яки башка камыр ризыгы өстенә шул рәвешле пумала белән рәсем ясагыз яки балаларның исемнәрен язып куегыз әле. Тәмлетамакларның сөенечтән башлары күккә тиячәк!

ПОМИДОР ҮСТЕРҮНЕҢ 7 КАГЫЙДӘСЕ

Бакчачылар чәчү-утырту эшләренә әзерләнә. Бик өлгерләре кайбер культураларны чәчте дә инде. Ләкин һәр нәрсәнең – үз вакыты. Укучыларыбыз игътибарына иң популяр яшелчә – помидор үстерү буенча «Шесть соток» басмасы киңәшләрен тәкъдим итәбез.

shutterstock.com

1 кагыйдә. Помидор үсентесен теплицага май башларында күчереп утыртырга уйласагыз, орлыкны март башларында гына чәчегез. Ә инде ачык туфракка утыртыласыларын апрель башына калдырыгыз. Гадәттә грунтка кырау төшү куркынычы беткәч, июньнең беренче декадасында күчерәбез. Соңрак чәчелгәнe, көн озынайганлыктан, яктылык күбрәк төшкәнлектән, тизрәк үсә. Шул ук вакытта орлык тизрәк шытып чыга, үсентесе ныграк була, әйбәтрәк үсә һәм помидоры да алданрак ярала.

2 кагыйдә. Үсентегә бик кечкенә булганда да туклыклы матдәләр кирәк. Шуңа күрә орлык чәчкәндә, туфракка, бигрәк тә туклыклы матдәләргә ярлы булган торфка ашлама кертергә кирәк. Иң яхшысы – комплекслы ашлама. Ул суда бик әйбәт эри һәм кирәкле барлык матдәләргә ия. Чәчү алдыннан «Акварин» (13 маркалы) кертүдән дә яхшысы юк. Эремә әзерләү өчен, 3 литр суга бер аш кашыгы ашлама салырга киңәш ителә.

3 кагыйдә. Савытка туфракны бик тыгызламыйча гына тутырырга кирәк. Өстенә ашлама эремәсен сипкәч, ул чама белән 1 сантиметрга утыра. Шуннан, туфракны тигезләп, орлыкларны тезәсе дә өстенә 0,6–1 сантиметр калынлыкта туфрак сибәсе була. Пленка яки пыяла белән каплап, җылы урынга куябыз. +24...+25 градуслы температурада орлыклар 4–5 көннән шытып чыга. Түбәнрәк температурада бераз тоткарлана.

4 кагыйдә. Тишелгәннән соң, яктырак һәм салкынчарак урынга куярга кирәк. Һава температурасы көндез +14...+16 градус булса әйбәт. Температура югарырак икән, үсенте соңрак чәчәк атачак. Ә иң мөһиме – төнге сәгатьләрдә температура көндезгегә караганда берничә градуска ким булырга тиеш. Юкса үсентеләр, нечкәреп, озынаеп үсәчәк.

5 кагыйдә. Орлык сай чәчелсә, тышчасы сабагына ябышып кала. Бу исә кәлшәнең үсешен тоткарлый. Тышчаны берничә тапкыр су белән җебетергә кирәк. Болай эшләгәндә, ул тиз кубып төшәчәк. Икенче чын яфрагы чыккач, ягъни тишелгәннән соң 10–14 көн узгач, аерым савытка күчереп утыртабыз.

6 кагыйдә. Кәлшәгә су урынына ашлама эремәсе сибәргә кирәк. Чөнки зур үсентегә караганда ул күбрәк ашлауны таләп итә. 2–3 яфрак чыгаргач, калий һәм кальций селитрасы эремәсе (берәр чәй кашыгы калий һәм кальций селитрасын 10 литр суга салып эретергә) сибү файдалы. Ә инде күчереп утырткач, «Акварин 8»гә (10 литр суга 1 аш кашыгы ашлама) күчәргә мөмкин. Үсемлекнең төбенә генә, кирәк булганда гына, аз-азлап сибәргә кирәк. Артык тиз үсә, дип, сипмичә торырга да ярамый. Юкса чәчәк атуы тоткарланачак һәм чәчәкләре азрак булачак.

7 кагыйдә. Савытларны якты урынга дөрес урнаштырырга кирәк. Үсентеләр берсен берсе каплап тормасын. 1 кв. м мәйданда күп дигәндә 20 төп үсенте үстерергә мөмкин. Яктылык өстән яфракларына гына түгел, бәлки кырыйдан сабакларына да төшәргә тиеш. Юкса алар нечкәреп, озынаеп үсәчәк. Урамда һава температурасы +10 градустан арта башлагач, кәлшәләрне балконга яки урамга алып чыгып чыныктыру яхшы.

Шушы кагыйдәләрне үтәгән очракта кәлшә тәбәнәгрәк, сәламәт, нык һәм ямь-яшел яфраклы булып үсәчәк.

Тәмле булсын!

КӘБЕСТӘЛЕ ТАВЫК КӘТЛИТЕ (Нина ВАСИЛЬЕВА рецепты)

Кирәк булачак: 300 г тавык фаршы, 100 г консервланган кукуруз, 100 г кәбестә, 1 чәй кашыгы кетчуп, 1 чәй кашыгы бөртекле горчица, 1 чеметем татлы паприка, 1 аш кашыгы үсемлек мае, 2 аш кашыгы су, тәменчә тоз, борыч.

Кәбестәне ваклап турыйбыз да тирән эчле савытка салабыз. Фарш, кукуруз, паприка, тоз, борыч өстибез. Яхшылап болгатабыз. Кәтлитләр әвәләп, майлы табага тезәбез. Кетчуп һәм горчицаны аерым савытка салып болгатабыз. Катнашманы кәтлитләр өстенә сылыйбыз. 2 аш кашыгы су салып, өстен фольга белән каплыйбыз. 180 градуска җылытылган газ мичендә 50 минут тотабыз. Пешеп чыгарга 5 минут кала фольганы алабыз.

Сорау – җавап

ШАМПИНЬОННАН АГУЛАНЫРГА МӨМКИНМЕ?

Бу гөмбәне бик яратам. Ләкин кибеттән сатып алганда һәрвакыт, агулы түгелме икән, дип шикләнеп куям. Ул агулы була аламы?

Нурания СИРАҖЕТДИНОВА. Казан

Укучыбыз соравына йогышлы авырулар табибы Марина Ковзун җавабы:

– Медиклар мондый хәлне бик сирәк очрата. Анысында да әле кеше үзе җыйган гөмбәнең агулы булып чыгуы аркасында гына. Теплицаларда үстерелгән гөмбә агулы була алмый. Аны хәтта, һич курыкмыйча, пешерелмәгән килеш тә ашарга мөмкин.

Исеңдә тот!

Үрмәкүчтән котылабыз

Әлеге бөҗәкне башмак белән шапылдатып юк итүне бәхетсезлеккә юрыйлар. Ә ничек котылырга? Аптекада сатыла торган бөтнек мае (масло мяты перечной) ярдәмендә! Ул аның исен яратмый. Моның өчен мамык тампонны майда чылатабыз да үрмәкүчләр күренгән урынга куябыз. Тампоннарны ике атнага бер тапкыр алыштыру киңәш ителә.

Ярты литр суга 20 тамчы бөтнек мае салып ясаган эремәне өйнең барлык почмакларына, ярыклы урыннарга һәм плинтусларга бөркеп чыгарга да мөмкин.

ҺӘР СОРАУГА БАР ҖАВАП

Көндәлек тормышыбыз сораулардан тора. Нәрсә хак, нәрсә ялган? Ничек дөресрәк? Бүгенге сәхифәбезне укучыларыбыздан килгән сорауларга багышларга булдык.

Сорауларга ачыклык кертүне сорап, Раил хәзрәт ФӘЙЗРАХМАНОВка мөрәҗәгать иттек.

?Беркөнне миңа бер танышым: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) Кәгъбә тирәсендә сәгать уңаена каршы йөргән, ә мөселманнар киресенчә эшли бит», – ди. Ничек дөресрәк икән?

Лилия ЗӘЙДУЛЛИНА

– Кәгъбәтулла тирәли без сәгать уңаена каршы йөрибез. Бу – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әмере. Ул үзе дә шулай эшли торган булган.

?Намаз укыны бер башлап, бер ташласаң, нәрсә була?

Шәфкать Г.

– Кеше бер мәртәбә намазга басып, мәшәкатьләр сәбәпле, намазын ташласа, соңрак тәүбәгә килеп, Аллаһтан кичерү сорап, гыйбадәткә кире кайтса, Аллаһы Тәгалә кичерер. Әмма сәбәпсез, Аллаһы Тәгалә хөкемнәреннән тайпылып, намазын калдырса, бу бик куркыныч. Кыямәттә Аллаһы Тәгаләнең газабы катырак булырга мөмкин. Намазга басу – зур бүләк. Намаз уку мөмкинлеген бик аз кешеләргә генә бирә. Аллаһы Тәгалә машинасын, йортын, байлыгын бөтен кешегә дә бирергә мөмкин. Әмма иман ләззәтен сайлап кына бирә. Мондый бүләкне югалтудан куркырга кирәк!

?Талак белән янау рөхсәт ителәме?

Хәмзә

– Аллаһы Тәгаләнең рөхсәт иткән, әмма иң яратмаган гамәле – талак. Кызганыч, аерылышулар бик күп хәзер. Югыйсә барысы да яхшы кебек бит. Ашарга ризыгыбыз, шкаф тулы киемебез, машинабыз, йортыбыз бар. Шуңа да карамастан, кеше гаилә корып, бәхетле яши алмый. ЗАГСта эшләүчеләр белән дә сөйләшкән бар. Алты мең кеше язылышса, шуның дүрт меңе аерылыша, диләр. Кызганыч инде бу. Кеше байлыгына, рәхәтлеккә түзә алмый. Хатынында яисә ирендә кимчелек таба. Үз парыңны бәхетле итмичә, син үзең бәхетле булмассың. Талак белән куркытудан сакланырга кирәк. Талак – җитди сүз.

?Куртка, футболка, майка киеп намаз укырга рөхсәт ителәме?

Руслан С.

– Әйе, футболка, куртка рөхсәт ителә. Майка димәктән, җилкәләр капланган булырга тиеш. Намаз әдәбен саклау хәерлерәк.

?Куас, хәмерсез сыра, хәмерсез шәраб, кымыз эчү, кальян, электрон тәмәке тартуга дин нинди карашта?

Исемем редакция өчен генә

– Сәламәтлек – әманәт. Аллаһы Тәгалә безгә аны вакытлыча гына кулланырга биреп торды. Динебездә: «Үзеңә дә, башкаларга да зыян китермә!» – дигән кагыйдә бар. Аллаһы Тәгалә дә: «Үзүзегезне үтермәгез», – ди. Ризык булсынмы, эчемлекме, физик күнегү булсынмы, бу күренеш кешенең саулыгына зыян китерә һәм бу расланган икән, алардан ераграк тору хәерле. Электрон тәмәке, кальянның зыяны турында табиблар да әйтә бит инде. Без сәламәтлекне сакларга тиеш. Градусы булмаган, кешене исертми, акылын җуйдырмый торган эчемлекләрне эчәргә ярый.

Хәмерсез саналганнарына килсәк, шик тудыра торганнарын кулланмаска кирәк. Әйтик, үзең намаз укыйсың, ә син кибеттән хәмерсез шәраб аласың, ди. «Кара әле, үзе мәчеткә йөри, үзе шәраб эчә!» – дип, сүз таралырга мөмкин. Намусыңа, динеңә тап төшерә алырдай әйберләрдән дә саклансак иде.

islam.ru

?Хатын-кызга, эшләмичә, ире тапкан акчага гына яшәргә ярыймы?

Раилә Г.

– Һичшиксез. Бу – динебездә хуп күрелә торган гамәл. Ир-ат, эти гаиләсен тәэмин итәргә бурычлы. Ул моның өчен җавап тотачак. Хатын-кыз өйдәге мохитне саклый. Искәрмәләр дә бар инде. Ир тапкан акча тормыш алып барырга җитми икән, хатын-кыз да эшкә чыга ала. Әмма ир-ат бар яктан, тулысынча гаиләсен тәэмин итәргә сәләтле икән, хатын-кыз өйдә торса хәерле. «Хатын-кыз – өйдән чыкса, ир-ат өйдә торса бозыла», – диләр бит әле. Гаиләдә тынычлык бетү сәбәпләренең берсе инде бу.

?Тиздән рамазан ае җитә. Каза калган уразаларым да күп. Ничә көн калганын якынча гына беләм. Каза калган уразаларымны төгәлләмичә, якынлашып килүче рамазан аенда яңа уразаларны башласам, гөнаһ буламы?

Гүзәл Т.

– Рамазанга кадәр барлык каза калганнарны тотып бетерергә тырышырга кирәк. Әлбәттә, җитди, саулыкка бәйле сәбәпләре булса, гөнаһы булмас. Әмма ялкаулык сәбәпле тотмый икән, гөнаһ та язылыр. Әгәр дә өлгермәсә, бу рамазан аенда ураза тота, тотып бетерә, рамазан ае тәмамлангач, барлык казаларны үтәргә тиешле була.

?Хәзер күпләр гомрә хаҗын кыла. Аның аермасы бармы?

Гөлнара

– Динебездә һәр мөселман үз гомерендә бер мәртәбә булса да үтәргә тиешле саналган 5 нигез, 5 багана бар. Шуларның берсе – олы хаҗ. Саулыгы, акчасы ягыннан мөмкинлеге булса, әлбәттә. Хаҗның гомрә дигәне (кече хаҗ) бар. Ул – олы хаҗның бер өлеше. Аермасы нидә? Олы хаҗ зөлхиҗҗә аенда гына кылынырга тиеш. Кече хаҗны исә ел дәвамында, кайсы вакытта телисең, шул вакытта үтәргә мөмкин. Зур хаҗ – фарыз (мәҗбүри) гамәл. Ә гомрә фарыз түгел. Зур хаҗда кайбер билгеле бер урыннарга бару да, анда дога кылу да күздә тотыла. Кече хаҗда алар булмый. Тагын бер аермасы: бәя ягыннан кече хаҗ зур хаҗга караганда арзанрак.

Хатыныңны бәхетле итү серләре

Белеп тор!

•Эшеннән яисә башка җирдән өенә кайтканда, ир кеше гүзәл йөз белән керергә, кулы белән күрешеп, гаиләсенә сәлам әйтергә тиеш.
•Хатыны белән мөлаем итеп сөйләшү, хатынның хәлләрен сораштыру тиешле. Хатынын ул ярата торган исемнәр белән чакырырга, дәшәргә кирәк.
•Ирләргә хатыннарын иркәләргә, аның белән уйнарга кирәк. Өйгә кайтканда да, киткәндә дә үбеп китү комачау итмәс.
•Ир хатынына өй эшләрендә булышырга тиеш. Хатыны бәби көткәндә аеруча да.
•Иргә хатын белән һәрвакыт киңәшләшергә кирәк.
•Ир кеше сәфәргә чыкканда, хатыны белән матур итеп саубуллашырга, күбрәк акча калдырып китәргә, кайтканда бүләкләр алып кайтырга тиеш.
•Бер-берсенең серләрен сакларга тиешләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): «Аллаһ каршында иң зур әманәт – ир белән хатын арасында булган серләр», – ди.
•Хатынына нәсыйхәт, гыйлем бирү, өйрәтү, тәҗрибә алышу хуплана.



pinterest.com

Йөгез, бер дога!

ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ МӨХӘММӘД (С.Г.В.) КӨН САЕН УКЫГАН

«Бисмилләһи, тәвәккәлтү гәләәллааһи үә ләә хәүлә үә ләә куүүәтә илләә билләәһ».

Мәгънәсе: «Аллаһ исеме белән Аллаһка тапшырылдым, Аңа ышандым. Көч һәм куәт бары тик Аллаһтандыр».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

ҮЛЧӘП СӨЙЛӘҮ

Әдәп башы – тел, дигән безнең халык. 3 февральдә Әдәпсез сөйләшү, сүгенү сүзләренә каршы көрәш көне икән. Мондый бәйрәмнең барлыгын белгәч, һәрвакыт игътибар үзәгендә булучылар – артистларның фикерен белешәсе иттек. Сәхнә кешесе сөйләгән сүзенә аеруча сак карарга тиеш бит инде. Ә гел шулай буламы икән соң? Эмоциональлек белән әдәпсезлекнең чиге кайда?

«Көтүдәге мал да борылып карамый бит...»

Җырчы **Алмаз МИРЗАЯНОВ** бу күренешкә өлешчә каршы түгел, аны хупламый да. «Диндә дә, әхлак нормалары буенча да сүгенү яхшы әйбер түгел, диләр. 90 проценты телән әйтелми, үзе чыгып китә бит ул... Ләкин ничек тә тыелып калырга кирәк. Матур да түгел бит ул, ә шулай да кайбер кешегә килешә. Нигә икәнен аңлата алмыйм», – ди ул. Аның фикеренчә, иң ямьсез күренеш – сүгенү сүзләре белән шигырь сөйләү, җыр җырлау. «Андый шигырьләр бик күп, ачу китереп, һаман саен җибәреп торалар. Сүгенеп куюның кирәк булган вакыты да бардыр ул. Интернетта минем бер ачынып язган постымны ачыктан-ачык кулланылган бер сүгенү сүзе аркасында гына игътибарга алганнары бар. Ул булмаса, алай ук көчле резонанс тудырмаган булыр иде. Көтүдә дә күзен тондырып чапкан малга «әйбәт» итеп эндәшмәсәң, борылып та карамый бит. Шуның кебек инде...» – ди җырчы. Шулай да, әхлаклы булып яшәргә кирәк, ди ул. «Бигрәк тә без – сәхнәдәгеләр тамашачыга үрнәк булырга тиеш. Атказанган, халык артисты исеме йөртүчеләр дә шушы зур җаваплылыкны онытмасыннар иде».

«Сәхнәдә авызны чамалап ачарга кирәк»

Бу җәһәттән җырчы, автор-башкаручы **Ләйсән МӘХМҮТОВА**ның да фикерен белештек. «Кызганыч, тормышта төрлечә сөйләшәм шул мин. Моның белән мактанмыйм да, яхшы дип тә санамыйм. Әдәп белән сөйләшү матуррак, билгеле. Кирәк вакытта үзеңне тыя белү – әйбәт нәрсә. Ләкин минем болай да кайнар каным тиз кыза шул... Берәр фикер белән килешмәгәндә, хаксызлыкка каршы чыкканда кирәкмәгәнен әйтеп ташлыйм», – ди ул. Ә сәхнәгә килгәндә, менә нинди фикердә Ләйсән: «Сәхнәдә ямьсезләнгән кешеләргә, теләсә нәрсә сөйләп йөрүчеләргә катгый рәвештә каршы мин. Аның урыны ул түгел. Бөек сәхнә матур сүзләр, акыллы фикерләр, якты хисләр, матур җырлар өчен яралган! Ә теләсә нәрсә сөйләп йөрүчеләр шул сәхнәне боза». Кыскасы, сәхнәдә авызны чамалап ачарга кирәк, ди ул. «Ә әдәп чиге – кешенең башында. Ул я бар, я юк».

«Беркемгә дә килешми»

Бу фикерне җырчы **Рафис КӘЛИМУЛЛИН** да дәвам итте. «Сүгенү, әдәпсез сүзләр сөйләү беркемгә дә килешми. Элек исем китми иде, хәзер ул күренешне бөтенләй яратмыйм. Балалар турында булса да уйларга кирәк. Алар бит безнең арттан кабатлый», – ди ул. Сәхнә кешесе теле өчен икеләтә җаваплы дигән фикердә ул. «Без бит халык алдында чыгыш ясыйбыз. Тамашачы бездән үрнәк алырга тиеш. Шуңа сүгенү түгел, гомумән, нәрсә сөйләшкәнне дә уйларга кирәк. Эмоцияләрне кулда тотарга өйрәнәсе иде», – дип сөйләде Рафис Кәлимуллин.

«Тәрбиядәндер ул...»

Җырчы **Ильвира ХАММАТОВА** өчен 30 яшькә кадәр иң ямьсез, иң әдәпсез сүз... «дурак» булган. «Бик каты ачуланган чакларга да, башка вакытка да туры китереп әйтә торган бердәнбер сүгенү сүзе иде ул минем өчен. Гаиләдән, тәрбиядән килә торган әйбердер ул, миңа калса», – ди җырчы. Бу күренешнең артистлар арасында да булуын кире какмый. «Эмоциональлеккә бәйледер инде ул. Сәбәбен шулай аңлатучылар да бар. Ләкин кеше гел эмоцияләргә генә бирелеп яши алмый бит. Ягъни эмоциональлеккә генә сылтап калдыру дөресме икән ул? Бәлки, әдәпсезлек, тәрбиясезлектән дә килеп чыгадыр ул?»

Бер сүз җитә

Уйламый әйтелгәне дә, әйтелми калганы да куркыныч. Сүзнең көче дә, тәэсире дә зур – моны һәркем белә, әмма кайчак тиешенчә бәяләми. Сәхифәбездәге яңа сорау – җавап та тормыштагы әһәмиятле сүзләргә багышлана. Бу юлы без Татарстанның атказанган артисты, алып баручы Гөлназ СӘФӘРОВА белән сөйләштек.

:: Иң кадерле сүз?
– Әни.

:: Бирешкәндә тартып торгызган сүз?
– Баш ярылып, күз чыкмаган.

:: Бик каты яралаган, рәнҗеткән сүз?
– Каргыш, каргап әйтелгән сүзләр.

:: Әйтәсе килеп тә, әйтә алмый калган сүз?
– Әйтеп барам кебек.

:: Бүген, хәзер ишетәсе килгән сүз?
– Йокла, ял ит!

Аннан-моннан

Узып баручы атнаниләр белән истә калачак? Бу сорауга җавап итеп, социаль челтәрләрдәге «кайнар» яңалыкларны тупладык.

Айсылу Габдинова өй туена әзерләнә. Җырчы һәм аның гаиләсе күптәнге хыялларын тормышка ашырырга – үз йортларына күчәргә җыена. «Гел өйдә яшәргә хыяллана идем. Эше күп икән аның», – ди ул социаль челтәрләрдә. Сүз уңаеннан, җырчы узган җәйдә генә тәүге мәртәбә әни булган иде.

ИлСаф – янәдән бабай! Җырчының икенче улыгы туган. Әлеге шатлыклы хәбәре белән социаль челтәрләрдә уртаклашты ул. «Бәхетле, мәрхәмәтле, иманлы бала булып үссен!» – дигән ИлСаф.

Юбилейлы атна. Бу көннәрдә Зинира Рамазановага – 35, Әнвәр Нургалиевка 50 яшь тулды. Татар эстрадасында «туып килүче» яңа модага ияреп, ике юбиляр да гомер бәйрәмнәрен сәхнәдә – тамашачысы белән бергә уздырды.

Таһировский – баш режиссер түгел. Узган ел ахырында, Венгриядә яшәүче татар режиссеры Сәрдәр Таһировский Әлмәт театрында баш режиссер булачак, дигән хәбәр чыккан иде. Театр директоры Фәридә Исмәгыйлева бу мәсьәләгә ачыклык кертте. «Бу мәгълүмат дөрес түгел. Безгә беркем дә билгеләнмәде», – диде ул.

Татарча көрәш – БРИКС уеннарында. Җәй көне Казанда узачак БРИКС илләре уеннарында матур көрәшебезне дөньяга күрсәтү мөмкинлеге булачак. Шушы сөенечле ноктада яңалыкларыбыз тәмам!

7 февраль | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ЖЫЛЫ ЭЗЛИ ЖАННАР» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 00.25 «Жырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башвакыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 21.25 «Ихсан күңел» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 04.20 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
03.30 «Зәңгәр томаннардан ак моң тама» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 10 лет со дня открытия Олимпийских игр в Сочи 12+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25, 17.25 «Сочи. 10 лет спустя» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 15.25, 18.25 Новости
07.05, 18.30, 21.50, 01.30 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Магия большого спорта» 12+
10.55 «Вид сверху» 12+
11.25 Профессиональный бокс. Василий Жиров против Джо Меси 16+
13.00 «Есть тема!»
15.30 «Жаркие. Зимние. Всегда твои. Сочи 2014»
19.00 Футбол. Winline Зимний Кубок РПЛ. «Спартак» – «Ростов»
23.25 Футбол. Кубок Испании. 1/2 финала. «Атлетико» – «Атлетик»
02.00 Лёгкая атлетика. Мировой тур в закрытых помещениях 6+
04.05 Мини-футбол. PARI-Кубок Лиги. Финал 0+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.55 «СПЕЦИАЛИСТ» 16+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.35, 04.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.35, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.55, 00.30 «Порча» 16+
13.00, 01.20 «Знахарка» 16+
13.35, 01.45 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «КОГДА СПАДЁТ ПЕЛЕНА» 16+
19.00 «КОГДА ТЫ МАМА» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 «Новости дня» 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.05 «СМЕРТЕЛЬНАЯ ОШИБКА» 12+
13.25, 03.45 «ДОРОГАЯ» 16+
15.00 «Военные новости» 16+
18.00 Карим Хакимов 16+
18.50 «Спецрепортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «КОНТРУДАР» 12+
02.45 «Нюрнберг» 6+
03.20 «Москва фронту» 16+

8 февраль | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «ЖЫЛЫ ЭЗЛИ ЖАННАР» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Татарлар» 12+
16.30 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
17.15 «Точка опоры» 16+
18.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Трактор» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Безнең Республика – безнең гамәл» 16+
00.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.50 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Точка опоры» 16+
03.30 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең жылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 Проект «Цивилизации» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Сочи. 10 лет спустя» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 16.25 Новости
07.05, 21.50 Все на Матч!
10.05, 12.35, 04.05 Специальный репортаж 12+
10.25 «Что за спорт?» 12+
10.55, 01.00 «Большой хоккей» 12+
11.25 Профессиональный бокс 16+
13.00 «Есть тема!»
14.25 Боулинг. BetBoom Кубок КЛБ
16.30 Футбол. Кубок равноправия. «Зенит» – «Шанхай Шеньхуа»
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Минск) – ЦСКА
22.55 Смешанные единоборства. UFC 16+
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» – «Локомотив» 6+
04.25 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Пермские медведи» – «Гомель» 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.55 «Поздняков» 16+
01.05 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
02.00 «Андропов. Между Дзержинским и Дон Кихотом» 12+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.30, 04.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.30, 02.40 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.20 «Знахарка» 16+
13.30, 01.45 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «БЕДНАЯ РОДСТВЕННИЦА» 16+
19.00 «НЕОКОНЧЕННАЯ СВАДЬБА» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 «Новости дня» 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.10 «СЫНОВЬЯ БОЛЬШОЙ МЕДВЕДИЦЫ» 12+
13.25, 05.00 «ПРАВО НА ПОМИЛОВАНИЕ» 16+
15.00 «Военные новости» 16+
18.00 Карим Хакимов 16+
18.50 «Спецрепортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДВА ФЕДОРА» 12+
02.40 «ЧУЖИЕ ЗДЕСЬ НЕ ХОДЯТ» 12+
04.00 «Нюрнберг» 16+
04.40 «Москва фронту» 16+

9 февраль | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести ПФО»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башвакыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 01.15 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.10 «КВН РТ-2024» 16+
23.40 «ТОЛЬКО СЕРЬЁЗНЫЕ ОТНОШЕНИЯ» 16+
01.40 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.55 Илсөя Бәдретдинова концерты 16+
03.55 «Башвакыч» 12+
04.45 «Жырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Жырлый Руслан Дәминов» 6+
08.30, 04.20, 18.20, 23.10 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
22.15, 02.30 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 12+
01.05 «Ирекле кубәләкләр» 16+
03.30 «Мин кайтырмын сезгә яңадан…» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос» 12+
23.30 «Матадор» 18+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе! Хором!» 12+
00.05 «Истории Большой Страны» 12+
01.05 «ДЕВУШКА С ГЛАЗАМИ ЦВЕТА НЕБА» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 «Третий тайм» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 08.10, 15.25 Новости
07.05, 15.30, 00.30 Все на Матч!
08.15, 04.05 «Небесная грация» 0+
08.35, 18.00 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
13.30 «Есть тема!»
14.55 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
15.55 Футбол. Кубок равноправия
18.40 Футбол. Winline Зимний Кубок РПЛ
21.00 Смешанные единоборства
22.30 Футбол. Чемпионат Германии. «Боруссия» – «Фрайбург»
01.30 «Что по спорту?» 12+
02.00 Боулинг. BetBoom Кубок КЛБ
04.25 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Виктор» – «Аист Китая» 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «Прошу, прости!» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
01.55 «Квартирный вопрос» 0+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 00.00 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.55 «Порча» 16+
12.55, 01.45 «Знахарка» 16+
13.30, 02.10 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.40 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Я ТЕБЯ НЕ ОТПУЩУ» 16+
19.00 «ПОБЕГ В НЕИЗВЕСТНОСТЬ» 16+
23.35 «Уютное утро» 16+
04.45 «6 кадров» 16+
04.55 «Предсказания: 2024» 16+
05.45 «ХОЧУ ТЕБЕ ВЕРИТЬ» 16+

ЗВЕЗДА
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 «Новости дня» 16+
09.25, 21.20 «Спецрепортаж» 16+
09.40 «…А ЗОРИ ЗДЕСЬ ТИХИЕ» 12+
14.05 «ИСЧЕЗНУВШИЕ» 16+
15.00 «Военные новости» 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.55 «ПОСОЛ СОВЕТСКОГО СОЮЗА» 12+
02.25 «КОРАБЛИ ШТУРМУЮТ БАСТИОНЫ» 12+
04.00 «Нюрнберг» 16+
04.45 «Перелом. Хроника Победы» 16+

10 февраль | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 01.15 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Дуслык илендә» 12+
14.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» – «Ак барс» 6+
17.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00, 04.45 «Кәмит Җавит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «ДВОЙНОЕ СЧАСТЬЕ» 16+
23.45 «БОЛЕВОЙ ПОРОГ» 16+
01.40 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
03.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Күрешергә вакыт табыйк» 16+
17.15 «Калеб» 6+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Язмышларым сиңа бәйләнгән» 16+
22.50 И.Зәйниев. «Мәхәббәт турында сөйләшик». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.05 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «Поехали!» 12+
12.15 К юбилею Ирины Муравьёвой 12+
13.25 «КАРНАВАЛ» 0+
16.25 К юбилею Николая Цискаридзе 12+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Я люблю мою страну» 0+
19.20 «Эксклюзив» 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.00 «Иван Лубенников: жизнь продолжается» 16+
00.20 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Веселья час» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВСЕМ ВЕТРАМ НАЗЛО» 16+
00.35 «ДВА БЕРЕГА НАДЕЖДЫ» 12+
04.10 «КОНТРАКТ НА ЛЮБОВЬ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Магия большого спорта» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 08.00, 18.45 Новости
07.05, 18.50, 22.30, 00.45 Все на Матч!
08.05 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
14.10 Футбол. Международный турнир «Кубок Легенд имени Константина Еременко»
19.55 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
20.25 Футбол. Чемпионат Германии
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.30 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
02.00 Смешанные единоборства. One FC 16+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.25 «Жди меня» 12+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион» 16+
23.25 «Международная пилорама» 18+
00.10 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.50 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Алексей Белов (Gorky Park) и оркестр «Глобалис» 16+
02.25 «Дачный ответ» 0+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.30 «Уютное утро» 16+
09.55, 02.20 «ТАКАЯ, КАК ВСЕ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.45 «КАРТА ПАМЯТИ» 16+
05.40 «ЗА ПЕРВОГО ВСТРЕЧНОГО» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «В МОЕЙ СМЕРТИ ПРОШУ ВИНИТЬ КЛАВУ К.» 12+
06.35 «НА ЗЛАТОМ КРЫЛЬЦЕ СИДЕЛИ...» 6+
08.00, 13.00, 19.00 «Новости дня» 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.20 «КОРТИК» 12+
11.10 «Мужики» 16+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды науки» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10, 19.25 «ЛЕТО ВОЛКОВ» 16+
22.50 «...А ЗОРИ ЗДЕСЬ ТИХИЕ» 12+
02.30 «КРАСНЫЕ ДИПКУРЬЕРЫ» 12+
04.05 «Нюрнберг» 16+
04.45 «Москва фронту» 16+

11 февраль | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 01.15 «Гомер китабы» 16+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 6+
11.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Татар сүзе» 12+
14.00 «Безнең Республика – безнең гамәл» 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «ГРОМКОЕ ДЕЛО» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Җитте шундый вакытларым» 16+
16.15 «Карурманны чыккан чакта...» 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җавит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 И.Мәхмүтова. «Мәхәббәт чишмәсе». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.20 К юбилею Н. Ерёменко 16+
15.15 «ПИРАТЫ XX ВЕКА» 12+
16.55 10 лет со дня открытия Олимпийских игр в Сочи 12+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «АБРЕК» 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.10, 02.20 «ПО СЕКРЕТУ ВСЕМУ СВЕТУ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
11.40 «Большие перемены»
12.40 «НЕЗАБЫТАЯ» 16+
17.00 Вести
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 К 300-летию Российской академии наук 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Что за спорт?» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 09.00, 13.05, 17.20 Новости
07.05, 13.10, 22.15, 00.45 Все на Матч!
09.05, 11.50 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
10.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
11.00 «Лица страны» 12+
11.20, 01.30 Биатлон с Дмитрием Губерниевым 12+
14.00 «Легендарный кубок» 12+
14.40 Футбол. «Кубок Легенд имени Константина Еременко»
17.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» – «Локомотив-Кубань»
19.30 Футбол. Winline Зимний Кубок РПЛ. «Ростов» – «Кайрат»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины 6+
04.05 Футбол. Чемпионат Германии 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
23.50 «Звезды сошлись» 16+
01.20 «Основано на реальных событиях» 16+
03.05 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ЗА ПЕРВОГО ВСТРЕЧНОГО» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
23.05 «ХОЧУ ТЕБЕ ВЕРИТЬ» 16+
02.35 «ТАКАЯ, КАК ВСЕ» 16+
06.00 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «ИСЧЕЗНУВШИЕ» 16+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Легенды госбезопасности» 16+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 12+
14.00 «Скрытые угрозы» 16+
14.50 «Секретные материалы» 16+
15.40 «Загадки века» 12+
16.30 «Улика из прошлого» 16+
17.20 «Спецрепортаж» 16+
18.00 «Главное» 16+
20.00 «Легенды советского сыска» 16+
22.35 «Москва фронту» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «КОРТИК» 12+
01.30 «ЛЕТО ВОЛКОВ» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Торак-коммуналь хуҗалык тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Балтачның күптармаклы торак-коммуналь хуҗалыгы производство предприятиесе» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Гарәфиев** Рәшит Фәрит улы; милли көрәшне популярлаштыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасының көрәш федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы **Гобәев** Марат Хөснулла улы; күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Җиһаншина** Нәзирә Рәшит кызы; яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тормыш иминлеге нигезләре укытучы-оештыручысы **Кәлимуллин** Наил Григорьевич; халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүдәге казанышлары һәм намуслы хезмәте өчен «Комфорт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Кукуль** Владимир Васильевич; җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Кара Алтын предприятиесе» ябык акционер җәмгыяте нефть һәм газ чыгару цехының электр һәм газ белән эретеп ябыштыручысы **Маркелов** Василий Михайлович, «СтройКом+» компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль краны машинисты **Никитин** Николай Егорович; республиканың урман хуҗалыгын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасының «Алабуга урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Мөхәммәтҗанов** Миңнегаян Таһир улы; законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Низамов** Эмиль Рафаэль улы, Татарстан Республикасы Арбитраж судының отставкадагы судьясы **Садыйкова** Зөлфия Әхмәт кызы; күпьеллык намуслы хезмәте, инвалидларның социаль проблемаларын хәл итүгә зур өлеш кертүе һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы – «Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасының Әгерҗе район оешмасы Кадыбаш бүлекчәсе рәисе **Рамазанов** Илфат Гали улы; җирле үзидарә органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Хәкимова** Гөлүсә Габделбәр кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы **Зиннәтуллин** Габбас Габделхәй улы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге башлыгы **Минголов** Рәфис Садыр улы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Анатыш авыл җирлеге башкарма комитеты эш башкару белгече **Мокроусова** Светлана Ивановна, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Паракова** Инна Владимировна, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы **Сәгыйтов** Вәзир Вазыйх улы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре башлыгы урынбасары **Салдаева** Роза Ягьфар кызы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Хәкимова** Гүзәл Гаяз кызы, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең оештыру идарәсе бүләкләр бүлеге башлыгы **Хәкимова** Ләйсән Зөфәр кызы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Хөҗҗәтова** Динә Камил кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Мөбарәкшина** Фәридә Рәис кызы; законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Арбитраж судының отставкадагы судьясы **Нәфиев** Илдар Фарук улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Восток Зернопродукт» акционер җәмгыяте механизаторы **Иванов** Виктор Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Социаль башлангычларга ярдәм фонды директоры **Гобәйдуллина** Эльмира Ринат кызына, «Транссервис» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе баш бухгалтеры **Ногманов** Рөстәм Рәмис улына, «Газпром төбәкарагаз Казан» акционер җәмгыяте бухгалтерлык һәм салым исәбе идарәсе башлыгы урынбасары – газны сатуга бухгалтерлык исәбе бүлеге башлыгы **Сафина** Ильмира Рәфкать кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының капиталь һәм агымдагы төзекләндерү программаларын үтәү бүлеге башлыгы **Уразаева** Алинә Рөстәм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы хезмәткәрләре: Экологик күзәтчелекне тәэмин итү үзәк бүлеге баш белгече **Борисович** Марина Григорьевнага, Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм экологик мониторинг идарәсе башлыгы **Гәрәева** Алия Дамир кызына **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Арбитраж судының отставкадагы судьясы **Абдрахманов** Илгиз Илдус улына, Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд составы рәисе **Мәннанова** Альбина Константиновнага, Татарстан Республикасы Арбитраж суды судьясы **Панюхина** Наталья Витальевнага **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

Свидетельство кт 381908 от 27.05.2022, выданное ГАПОУ «ААПК» на имя Маннанова Айдара Фанисовича, считать недействительным в связи с утерей.

СЫНМАС(МЫ) КАНАТЛАР

КАМИЛӘ ВӘЛИЕВАГА БӘЙЛЕ КАРАРГА БЕР КАРАШ

vk.com

Җәмәгатьчелеккә көтелгән һәм көттергән карар билгеле булды: Спорт арбитраж суды (CAS) фигуралы шуучы Камилә Вәлиеваны 4 елга дисквалификацияләде, ягъни спорттан читләштерде. Моның белән бергә спортчы кызның соңгы еллардагы барлык казанышлары да юкка чыгарыла дигән сүз. Россия җыелмасы да җиңүче исеменнән мәхрүм калды. Әлеге җитди карарга килгән кешеләрнең утырышы ике еллап барды. Тик нәтиҗә тагын да күбрәк сораулар уятты. Ә кем җавап бирер?

«Карьерасын гына түгел, тормышын да сындырмагайлары»

Допинг кагыйдәләрен бозган өчен карар җәзасы төрле була ала. Камиләгә исә иң кырысы эләкте. Җәзаның кимрәген дә биреп була иде. Татарстанның элеккеге спорт министры, республиканың Олимпия Советы рәисе Марат Бариев әйтүенчә, карарның кырыслыгы – спортның сәясәт уенына әйләнә бару нәтиҗәсе дә.

– Җинаять кодексында да фәлән елдан фәлән елга кадәр дигән сайлау мөмкинлеге бар. Биш ел да биреп була, унбиш ел да, дигәндәй. Камилә очрагында да шулай. Җәзаның иң зурын сайладылар әнә. Бәйләнергә мөмкинлек бар бит, – диде ул «ВТ» хәбәрчесенә. – Кызганыч, бу очракта таякның каты башы милләттәшебез Камиләгә эләкте.

Нишләп шушыңа кадәр килеп җиттек соң? Марат Бариев әйтүенчә, бу карар җавaплардан бигрәк күбрәк сораулар гына тудыра.

– Кем карап бетермәгән? Тренерлары, командасы, табибларымы, Спорт министрлыгымы, Олимпия комитетымы? Ике елдан артык вакыт узды. Ә без берни белмибез диярлек. Безнең яктан, безнең ил эчендә тикшерү барамы? 15 яшьлек кыз кулына ул дару ничек килеп эләккән? Мин аның үз белдеге белән аны куллануына һич кенә дә ышанмыйм. Гаепле кеше табылса, җәзасы булырмы? Сораулар бик күп. Допинг-проба алынганга күпме вакыт. Безнекеләр ник алданрак кызыксынмаган? Ник Камилә Олимпия уеннарында чыгыш ясаганнан соң гына килеп чыкты бу хәл? Алданрак белсәләр, мондый хәлләр булмас, Камиләне башка спортчы белән алмаштырып булыр иде. Хәзер иң мөһиме – Камилә нишләр? Камиләгә хәзер – 17 яшь. Аңа ике ел дәвамында нишләргә? Аңа булышу каралганмы? Бу хакта уйлаучы бармы? Спортта булмаса, башка юнәлештә ярдәмгә өметләнеп буламы?

«ВТ» әңгәмәдәше фикеренчә, бу вакыйга спорт сөючеләргә (бигрәк тә яшьләргә) дөньяда шундый гаделсезлек очраклары барлыгын да күрсәтәчәк. Аерым алганда, Россиягә карата булган мөнәсәбәтне.

– Әлбәттә, Камиләне барыбыз да ярата, хуплый, борчыла. Хәтта безнең илдәге халык кына түгел, дип әйтер идем. Күптән түгел генә чит илдә булдым. Әле Камиләгә бәйле карар билгеле түгел иде ул чакта. Анда да спортны яратучылар, аңлаучылар Камиләнең гаебе юклыгын бик яхшы белә, аның өчен кайгыра, – диде Марат Бариев. – Камилә – фигуралы шуудагы иң сәләтле кыз. Андый икенче кеше тиз тумас та әле. Андыйлар йөзгә бер генә туа. Камилә аерылып тора, башкалардан бер башка югарырак иде. Фигуралы шуу үсеше өчен, әлбәттә, тискәре карар бу. Ул фигуралы шууның матурлыгына тап төшерәчәк. Хәер, хәзер нидер үзгәртергә дә соң... Әмма киләчәктә шундый нәрсәләр булмасын өчен тырышырга кирәк. Әйтик, Казанда зур ярышлар булырга тора. Игътибар бик көчле булачак. Шушы чараларда ун спортчының берсендә шундый хәл булса? Бу вакыйганы ничек күпертәчәкләр бит! Камилә әнә шундый вакыйгалар кабатланмасын өчен бик зур бәя түләде инде.

Уртак гаеп

Гаепне үзебездән дә эзләргә кирәк. Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов Камилә Вәлиевага карата бирелгән җәза турында әнә шундый фикердә. «ВТ» хәбәрчесе белән сөйләшү вакытында әлеге вазгыятькә карата тагын менә нәрсә диде ул:

– Халык та борчыла, әлбәттә. Әмма гаеп бездә дә бар. Спортчыны андый хәлдә калдырырга тиеш түгел идек. Ул бит – япь-яшь кыз! Җитәкчеләр, функционерлар, тренерлар, табиблар уйлап бетерергә тиеш иде моны. Гаепне үзебездән дә эзләргә кирәк. Акыллы кеше чишелешен табар, ә зирәк кеше бу хәлне булдырмый калыр иде, диләр бит. Камиләдә әле яшенә күрә олылар зирәклеге юк, шулай булгач, алар да күз уңында тотмаган. Камилә белән генә түгел, бүтән спортчылар белән дә мондый хәл кабатланмасын өчен, алдан хәстәрен күрергә тиешләр. Допинг кулланырга ярамаганын кем дә белә. Камилә кулланган матдә аңа берничек тә ярдәм итмәвен аңлыйбыз. Мин ышанам: әле Камилә өчен көрәшерләр, нәрсәне дә булса үзгәртергә тырышырлар. Бәлки, карарны ике елга гына калдырырлар дип өметләнәбез. Мин шәхсән өметемне өзмим әле. Соңгы елларда спорттан сәясәт мәйданы ясадылар. Элегрәк спорт ул матурлык, нәфислек, көч урыны иде, без шуларны күрдек. Хәзер бу төшенчәләр үзгәрә башлады. Яшь кызны кыерсытып, безне дә кыерсытмакчылар, күрәсең. Халыкны, халык ярата торган кешеләрне ягъни. Күреп торабыз бит: бүген акны кара дип, караны ак дип төртеп күрсәтәләр. Бүген бөтен дөнья безгә ябырылган. Карар шундыйрак булыр дип чамалаган идем. Әмма безне яклаучылар күбәйде. Азия, мөселман илләре, дисеңме. БРИКС уеннарын, «Киләчәк уеннары»н оештырырга җыенабыз. Без хаклык белән җавап бирәбез.

Күңелле түгел

Биология фәннәре докторы, КФУ профессоры Рөстәм Абзаловны да Камиләгә бәйле карар бер дә гаҗәпләндермәгән.

– Нәрсә дип әйтәсең инде монда? Бик кызганам ул кызны. Каныктылар бит шуңа! Башка ил вәкиле булса, бәйләнүче булмас иде, ә ул менә нәкъ тә Россиядән булуы белән игътибарны җәлеп итте. Үзенекеләре исә – үзәктә, – диде ул, хискә бирелеп. – Препаратның (триметазидин турында сүз) көтелмәгән тәэсиренә (побочный эффект) координациягә йогынты ясау керә. Фигуралы шууда координация иң мөһиме бит. Димәк, ультра-си элементын ясау, катлаулы сикерүләр башкару мөмкин булмас, баш әйләнер иде. Олимпия уеннарында да кызны чак кына сындырмадылар бит. Спортчыларга бик күп нәрсәдә чикләүләр бар хәзер. Әйтик, без сезнең белән иртән каһвә эчсәк, берни булмас. Ә спортчылар иртән каһвә эчсә дә, нидер табарга мөмкиннәр. Шуңа да алар нәрсә, ничек, нинди күләмдә – барысын да тикшереп торырга тиеш. Хәзер кырын эштә тотылу бик җиңел. Шунысы кызганыч: спорт салкын сугыш кырына әйләнеп бара. Ә сугышта нәрсә дә бата. Илләрнең көче һәрвакыт корал, фәнни уйлап табулар, спорт белән бәяләнде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Мөнәсәбәт

Илнар ХӘСНУЛЛИН,
«ВТ» газетасы баш мөхәрриренең беренче урынбасары:
– Ике елга сузылган билгесезлектән соң чыккан карар үзе түгел, Камилә Вәлиевага җәза бирелгәч, аһ-ваһ килүчеләр күбрәк гаҗәпләндерде. Ә сез чынннан да башкача булыр, ачуланырлар да кичерерләр яки йомшаграк җәза бирерләр дип өметләндегезме? Көнбатыштагы спорт түрәләре мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырыр дип уйладыгызмы? Юк, әлбәттә! Белә бит инде алар да: кайсы урынга ничек суксалар ныграк авырттырасын чамалыйлар. Бүгенге заманда бигрәк тә. Зинһар, гаделлек һәм намус турында әйтә күрмәгез: зур абзыйларның сугышында 17 яшьлек кыз баланы корбан иткәндә андый төшенчәләргә урын юк. Спортта сәясәт булды, бар һәм һәрвакыт булачак. Алдамыйк үзебезне! Алдамыйк, димәктән, ул допинг турында дөреслекне кайчан да булса белеп булырмы? Һәркемнең үз дөреслеге бит.
Камилә җәза бирелгән беренче спортчы түгел һәм соңгысы да булмаячак. Дөньясында әллә ниләр булып ятканда, спорт кына чиста кала алмый бит инде. Медальне дә алалар, җиңүчеләр исемлегеннән дә сызып аталар. Әле тиз арада онытаалр да. Тик бу очракта иң аянычы – өметне юкка чыгаралар. Безнең өмет – балаларда. Ә бу хәлләрне күреп торган балаларга ни әйтергә? Алар бит сорау бирә: инде Камиләне дә саклый алмагач, безне яклармы? Инде Камиләне дә юкка чыгаргач, безнең киләчәгебез булырмы? «Әйе», – дип әйткәнгә генә ышанмаслар шул. Сүз генә җитмәячәк. Эшләргә дә кирәк.

«ТӘГӘРМӘЧЛЕ» КИТАПХАНӘ

КИТАП УКУЧЫНЫҢ ӨЕНӘ ҮЗЕ КИЛӘ

Китапханәләре булмаган кечкенә авылларга рухи байлыкны күчмә китапханә китерә. «ВТ» хәбәрчесе Балык Бистәсе районында китапханәче булып эшләүче Гөлсинә Сәлахиева белән авыл урамнары буйлап йөреп, абунәчеләрнең китапка мөнәсәбәтен белеште.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гөлсинә Сәлахиеваны һәр йортта көтеп алалар.

Әйләнә китап, әйләнә

Күчмә китапханә ул – китапханә булмаган җирлекләргә хезмәт күрсәтү. Аны булдыруны, китапханәчегә юл хакын түләүне районнар үзләре хәл итә. Күчмә китапханәләр районлардагы үзәкләштерелгән китапханә системасына буйсына. Күбесе клуб бинасында урнашкан. Китапханәче атнага 1–2 мәртәбә билгеле сәгатькә генә килеп китә. Килә алмаучы әби-бабайларга, авыруларга исә китап, газета-журналларны өйләренә илтәләр. Шәһәрләрдә бу хезмәтне мобиль микроавтобуслар күрсәтә. Әйтик, Казанда «Библиобус» дигән күчмә комплекс бар. Китап тарату белән башкалада 6 китапханә шөгыльләнә.

Гөлсинә Сәлахиева Казан дәүләт мәдәният институтын тәмамлап, инде 36 ел Яңа Сала авылы китапханәсендә эшли. Шул ук вакытта Яңавыл һәм Чаллыбаш авылларындагы күчмә китапханәләрдә дә хезмәт күрсәтә. Алар клуб бинасында урнашкан. Анда китапханәче хат ташучы кебек кадерле. Гөлсинә апа атнага бер тапкыр билгеле сәгатьләрдә килә. Яңа китаплар тәкъдим итә, төрле чаралар уздыра. Яңавылдагы китапханәне сентябрь аенда сүткәннәр. Кыска вакыт эчендә иганәче ярдәме белән яңасы төзелгән. Тиздән ачылыр дип көтәләр.

– Китап кирәк булса, әллә каян эзләп йөрмиләр. Миңа шалтыратып: «Безгә фәлән китап кирәк, шуны алып кил әле», – диләр. Газета-журналлар да китерәм, – ди юлдашым. – Авылларның картаюы китап укуны сүлпәнәйтә. Кечкенә авылларның кайберләрендә кибет, клуб, башка социаль объектлар юк. Өлкәннәрнең күбесе – өйдә. Гел телевизор гына да карыйсы килми. Шуңа күрә китап укып юаналар. Аларга аралашу җитми. Башта хәлләрен белешәм. Аннан укыган әсәрләре, газета-журналлар турында фикерләр алышабыз. Эшебез шундыйрак. Өч авылга 430дан артык китап укучы бар. Шуның 100е күчмә китапханәдә укыса, 50сенең өенә илтәбез.

Яшерми: баштарак авыл буйлап, җәяү китап күтәреп йөрү кыенга туры килгән. Хәзер ул үзе – рульдә. Китапларны төйи дә «күчмә китапханә»гә чыгып китә. Гөлсинә апа белән башта төп китапханәдә исемлек буенча китапларны барладык. Ул инде һәр укучысының зәвыгын белә. Әйтик, Фәрит Сафин тарихи романнар яратса, Рәшидә Шәйхетдиновага гыйбрәтле язмышлар кирәк. Ә менә кечкенә Сәйдәгә дип сумкасына рәсемнәре күп булганын тыкты. Арада якташ шагыйрьләре, язучыларныкы да күренде. Яшьләр өчен әдәп-әхлак темасына әсәрләр, шулай ук детектив, фантастика җанрларын сайлады. Яшьләр, урта буын күчмә китапханәгә үзләре килгәли. Элек балалар активрак булган. Мәктәптән кайтканда, китапханәдә 2–3әр сәгать утырып кайтып киткән. Хәзер өй эшләре күп, ахры.

– Китап яратмыйм дигәнне ишеткәнем юк. Күзем начар күрә, диючеләр бар. Билгеле, андыйларны мәҗбүри укытып булмый. Китапны көнбагыш урынына чиртүчеләр дә бар. Элеккеге бакча мөдире Гөлшат Имамиевага җиткереп булмый әнә. Моңа кадәр ягулык станциясендә эшләгән, хәзер лаеклы ялда булган Резеда Шәрәфетдинова да кимен куймый. Әлфинур Шәрәфиева да ләззәтләнеп укый. Яңа Салада мәрхүм Фариз Кәримуллинның китапханәгә керми калган көне юк иде, – дип, рекорд куючы абунәчеләрен барлады Гөлсинә апа.

Китап яратмаучыны күп нәрсәдән мәхрүм дип саный ул. «Ничек аны яратмаска мөмкин?» – ди Гөлсинә апа, үзе үк сорау биреп. Халык китап укудан бизмәде дигән фикердә ул. Уздырган чараларының барысын да китапка бәйләргә тырыша. Кызыклы итеп сөйләгәч, укыйсы килмәгән җиреңнән укыйсы килә башлыйдыр, мөгаен.

Яңа Сала авылында яшәүче 78 яшьлек Равил абый Рәхмәтуллинның да өенә барып, хәлен белештек. Китапны 1 нче сыйныфтан бирле укый ул. Абзый берьюлы 2–3 тарихи китап алып калды. Юлда актив укучы Резеда Шәрәфетдинованы да очраттык. Аның күңеленә авыл, милләт, дин темасы якын икән. «Китап уку – канда. Бер тәмен белгән кеше рухи байлыктан берничек тә бизә алмый», – дип ышандырды ул. Дөрес, яшьләр арасында «китап бирегез» дип алырга атлыгып торучылар аз. Әмма китапханәче хәйләсен табып: «Әйдә әле, менә монысын, тегесен укып кара. Аннары фикереңне әйтерсең», – дип балаларның күңел кылларын тарткалый. Шулай аңлатканда, китапханәче үзе өйгә килгәндә каршы килеп була димени? Әнә Ильяс башта читенсенебрәк торса да, «Ярый, апа, укырмын», – дип ышандырды.

Чаллыбашта 36 хуҗалык исәпләнә, 135 кеше яши. Шуларның 100дән артыгы күчмә китапханәгә язылган. Гайнетдиновлар китапны гаиләләре белән укый икән. Без дә аларга сугылдык әле. Әбиләре Рузилә апа дини темаларны ярата. Шулай ук әдәби әсәрләргә дә битараф түгел. 6 нчы сыйныфта белем алучы Ралинә өйдә юк иде, ул да бик актив укучы икән. 8 нче сыйныфта укучы Рәсүлгә «Балаларга үгет-нәсыйхәт» дигән китап калдырса, 4 яшьлек Руфинәгә икенче юлы рәсемлесен алып килергә сүз бирде. «Мәктәпкә хәзер укырга өйрәнеп керәләр. Китапны яратырга кирәк», – дип киңәшләрен бирде Гөлсинә апа сабыйга. Сөйләсәң, аңлатсаң, күрсәтсәң, һәр күңелгә ачкыч табып була, димәк.

> **Сан**
>
> Татарстан Мәдәният министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, хәзерге вакытта республикада **1507** китапханә исәпләнә. Шуларның **1297**се авыл җирлегенә карый. Китапханәләрнең **95,2** проценты – клуб, **72**се аерым бинада урнашкан. 2019–2023 елларда «Мәдәният» илкүләм проекты ярдәмендә **14** китапханә ачылган һәм яңартылган. Шуның **7**се – авылларда. Авария хәлендәге китапханәләр юк.

Башкаларда ничек?

Мөслим районында 41 авыл булса, шуның 27сендә китапханә бар. Булмаганнарына җирлектәге китапханәчеләр хезмәт күрсәтә. Мари егете 45 яшьлек Виталий Мухдин Мари Бүләр китапханәсендә эшли. Шулай ук атнага ике тапкыр 4 чакрымдагы Осиновка авылына барып та китап таратырга өлгерә. Анда 14 йортта 41 кеше яши.

Моңа кадәр агрофирмада сыер сауган. Китап укырга яратуы аны китапханәче белеме алырга этәргән. Әлеге хезмәттә – биш ел. Виталий үз эшен бик яратып башкара.

– Осиновкада китапханә юк. Яшьләр аз, күбесе – өлкәннәр. Әби-бабайлар интернет белән дус түгел. Шуңа күрә һәр йортта сагынып көтеп торалар. Иң өлкән китап укучыбыз – 85 яшьлек Миңлекай Үтәбаев. Барысы да – 41е дә укый. Сан өчен генә әйтүем түгел, дөресе шулай. Безнең эш – укырлык итеп кызыксындыру. Татар, мари телендәге газета-журналлар, китаплар укыйлар. Клуб мөдире белән бер йортта Өлкәннәр көне үткәрәбез. Чәй әзерлибез, бүләкләр бирәбез. Җиңү көнендә дә хәл белешәбез. Бәйрәмнәрдә күңелләрен күрергә тырышабыз, – ди Виталий Мухдин.

Китапханәче Альбина Романова Яңа Усы авылында яши. Ике авылдагы күчмә китапханәдә хезмәт күрсәтә ул. Бикмәчтә – 54, Горбуновкада 5–6 укучысы бар.

– Авылда халык саны азая, шуңа күрә китап укучылар да кими. Күчмә китапханә булу бик әйбәт. Үзем машина йөрткәч, авырлыгын күрмим. Китапны укып бетергәч, тагын кирәк, дип шалтыраталар. Кайчак атнага бер, икеөч тә баргалыйм. Күбрәк матур әдәбият тәкъдим итәм. Бакчачылык, сәламәтлек турындагы китап, журналларны сорыйлар. Авыл кешесен бигрәк тә язмышлар, авыл кешесенең яшәеше кызыксындыра. Үзебезнең якташ язучылар Фоат Садриев, Факил Сафин, Зөлфәт һәм башкаларның китапларын да яраталар, – ди 12 ел китапханәче булып эшләүче Альбина Романова.

Арча районының Яңа Сала авылы китапханәчесе Фәридә Борһанова Каенсар авылы халкын китап белән тәэмин итә. 35 ел шулай! Әлеге авылда 50 хуҗалык исәпләнә. 125ләп кеше яшәсә, шуның 90ы китап укый.

– Авылда кибет, мәктәп тә юк. Клуб кына бар. Күчмә китапханә шунда урнашкан. Ялгыз яшәгән әбиләрнең өйләренә йөрибез. 15енең янына барам. Газета-журнал, китап илтәм. Арада 76 яшьлек Сәвия апа Газизова кебек көн саен бер китап укыганы да бар. Халык китаптан бизмәде, аларга яңасы кирәк. Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахуновны кат-кат укучылар бар. Кайберләре газета-журналдагы сканвордны чишү өчен чиратт тора. Яшьләр шәһәрдә бит хәзер. Каникулга кайтучы балалар белән актив эшли башладым әле. Атна саен 15ләп бала кайта. Алар китапханәгә исемлек тотып килә. Мәктәптән кушалар, димәк. Әби-бабайга кайтып, китап укып китәләр, – ди Фәридә апа Борһанова.

Сәрия МИФТАХОВА

КУКМАРАДА ЯШӘҮЧЕ ИЛДУС ХАФИЗОВ:

«ТОРМЫШНЫ ЯРАТСАҢ...»

Зур Кукмара авылында яшәүче 68 яшьлек Илдус Хафизов кар ишеп яуган көннәрдә урам җыештырырга чыгып, бөтен дөньяга танылды. «Кар көрәүнең нәрсәсе бар инде?!» – диярсез. Тик Илдус абыйның бер аягы юк шул. Култык таягы белән йөри, бар эшне урындыкка утырып эшли ул.

Хәлләрен белешеп шалтыратканда, хатыны Люция апа белән чәй эчкән вакытлары иде. Берберсен бүлдермичә, чиратлап кына сөйләштеләр алар.

– Илдус абыегыз үзе шундый көчле рухлы кеше инде ул. Берәү булса, бер аягым юк, дип ятар иде. Ә ул, шөкер, моңа игътибар да бирми. Һәр эштә ярдәм итеп, башкаларга да, миңа да үрнәк булып яши, – дип ирен мактап сүз башлады Люция апа. – Иремнең кан тамырлары тыгылып тилмертте. 14 операция ясатты. Унбишенчесенә барган иде, табиблар, аякны кисмичә булмый, дип кайтарды. 2018 ел иде бу. Аяксыз калуына алдан әзерләдә үзен. Башка кешеләрне үрнәк итеп куйды. Инде сызланулардан арыган иде. Шуңа да ризалашты.

Илдус абый бөтен эшне урындыкка утырып эшли икән. Йорттагы ир-ат эшләрен үзе башкара. Узган ел да кар көрәшкән. Быел да түзеп тормаган. Люция апаны кызганып, көрәргә чыккан. Илдус абый аягын кисәсе елны яңа машина да алган була. Бер дә аптырамый, тота да кул белән идарә итә алырлык итеп ясата. Җәйләрен рәхәтләнеп җиләк җыя икән, бакчада да булыша. Бәрәңге дә ала, хәтта урындыгына утырып казый да.

– Икебезнең дә йөрәк яралы безнең. Гомеребез буена җитәрлек хәсрәт белән яшибез. Моннан 7 ел элек улыбыз Динар кинәт кенә үлеп китте. Кибеткә киткән җиреннән кире кайтмады. «Йөрәк», – диделәр. Өйләнгән дә иде балакаем. Киленем белән матур гына яшәп яталар иде. Баласы туарга өлгерми калды. Шөкер, оныгыбыз белән дә, киленебез белән дә аралашып торабыз. Ял көннәрендә оныгыбыз безгә дә килә. Улымның истәлеге булып калды ул, – ди Люция апа. – Лилия исемле кызыбыз бар. Аның үз гаиләсе. Азнакайда яшиләр иде. Без икәү генә калгач, Биектауга күченделәр. Кайтып йөрергә дә якын хәзер. Әле дә шул балалар бар. Ташламыйлар.

Быел Илдус абыйның сәламәт аягы сызлый башлаган әле. Дарулар эчеп кенә тора икән. Әмма күңелен төшерми.

– Минем кебек кешеләр күп инде ул. Аяксыз калсаң да, күңел көрлеген югалтмаска кирәк. Тормыш дәвам итә. Гомер тиз үтә, аны әрәмгә уздырырга ярамый. Әнә шуңа да мин үземнең аягым юклыкны кайчак онытып та җибәрәм. Әле ярый култык таякларым бар, – ди ул. – Яшисең килсә, бар нәрсәгә җайлашасың икән. Мин бер дә зарланмыйм. Тормышыбыз шөкер итеп яшәрлек. Ныклы терәгем бар: Люция апагызга рәхмәт! Ул булмаса, белмим, нишләр идем?! Бергә озак еллар матур итеп яшәргә язсын.

Бала хакы

Азнакай районының Актүбә бистәсендә яшәүче 46 яшьлек Марсель Ханнановка ярдәм кирәк. 16 ел шикәр чире белән интеккән ир инде хәзер йөри алмас хәлгә килгән. Аны 67 яшьлек әнисе Рәйсә апа тәрбияли.

Марсель армиядән соң Мәскәүгә эш эзләп чыгып киткән. Тик күпме генә тырышса да, юлы уңмаган. Кызларына 2 яшь вакытта хатыны белән дә аерылышканнар.

– Тормыштагы күңелсезлекләре сәбәп булдымы, улым авырып китте. Көчле стресс кичергән, диде табиблар. Шикәре 20гә менгән иде. Менә шуннан башланды инде хастаханә юлларын таптау. Йөри торгач, III группа инвалидлык бирделәр. Аннары кан тамырлары белән проблемалар башланды. Бер чир артыннан икенчесе килеп чыкты, – дип сөйли Рәйсә апа. – Марсель – олы балам. Аннан соң тагын бер улым белән кызым бар. Алар икесе дә гаиләле.

Рәйсә апа белән Марсель, ике ел элек авылдагы өйләрен сатып, Актүбәгә күчкәннәр. Шәһәр фатиры улы өчен уңайлырак чөнки.

– Моңа кадәр улым үзе йөри иде әле. Табибларга да гел күренеп торабыз инде. Инвалидлыгын да II группага күчерделәр. Тик аңа карап кына кирәк-яраклар бирелми шул. Тик мин зарланмыйм. Быелдан пенсиям артып китте. 23 мең сум алам. Улымныкы күп түгел, 10 меңгә дә тулып җитми. Әле бит ул урында ятса да, 23 яшьлек кызына алимент түли. Эшли алмаган вакытта җыелган әҗәтләрен хәзер түләтәләр, – ди Рәйсә апа. – Оныгым белән сөйләшеп торам. Әтисенең авырып китүен дә әйттем инде. Фотосын да төшереп җибәрдем. Киленем дә, кызы да хәлемне беләләр, тик кайтканнары юк. Марселем быел 35 килограммга гына калды...

Рәйсә апаның пенсиясен коммуналь хезмәтләргә, азык-төлеккә тоталар, Марсельнеке даруларына да җитми икән. Рәйсә апа буш вакытында таксида эшли, машина йөртә.

– Ирем дә иртә китеп барды. 9 ел элек, 61 яшендә эчем, башым авырта дип бер атна йөрде дә үлеп китте, – ди Рәйсә апа. – Күңелем ышана, улым аягына басар, дип уйлыйм. Кулдан килгәннең барысын да эшлим, ашатырга да тырышам, каннарын да тикшереп торам, даруларын да вакытында бирәм. Бер генә теләгем – сабыксын иде.

Марсельгә ярдәм итәргә теләүчеләр әнисе Рәйсә Рәис кызы Ханнанова исемендәге Саклык банкы картасына акча күчерә ала. Карта **89870650203** телефон номерына беркетелгән.

Узган елның 10 апрелендә Актаныш районының Буаз Күл авылында янгын чыккан иде. Бер урамдагы биш йорт янып бетте. Ул йортларның берсе хуҗасыз, калган дүртесенең ияләре булган. Ике йортны сатып алган кешеләр читтә яшәгән, ә менә ике гаилә өчен әлеге нигезләр бик кадерле булган.

НИГЕЗЛӘРЕНДӘ – ЯҢА ӨЙ

Исегезгә төшереп үтик: аның берсендә 83 яшьлек Әспира Нәбиуллина, икенчесендә Зөлфәт Фазлыйәхмәтов яшәгән. Ул чакта без бу гаиләләр турында язган идек. Ярдәм итүчеләр дә булды. Хәер, әлеге хәбәр бөтен дөньяны гизеп чыкты дисәң дә, арттыру булмас. Әспира апаның кызы Раушания сүзләренчә, алар инде әниләренә башка йорт җиткереп булмас дип тә уйлаганнар. Тик ике гаиләгә дә бер белмәгән кешеләр булыша башлый.

– Без, ике кызы, әнине чиратлап үзебездә яшәтербез, дигән идек. Әмма ул, үз нигезем, дип борчылды. Сүз дә юк, янган йорт үзебезгә дә кадерле иде. Монда балачагыбыз узды. Аллага шөкер, мәрхәмәтле авылдашларыбыз, интернеттан күреп булышкан мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән әниебез йортлы булды. Узган елның ноябрендә яңа өйгә чыкты. Коръән ашы да уздырдык, – ди Раушания. – Ул янгын онытырлык булмады. Әниебез инсульт кичереп, бик авыр гына йөри иде. Без аны бик кадерләп кенә яшәттек. Күпме генә кыстап үзебездә яшәтсәк тә, ул гел, үз өем, диде. Бик чиста, пөхтә кеше ул. Бар җирне ялт иттереп торды. Үз нигезебезгә яңа йорт салып керә алуыбызга шатбыз. Әниемә булышкан һәр кешегә чиксез рәхмәт. Безнең авыл халкы болай да бердәм иде. Ә инде авылдагы янгыннан соң тагын да берләштек. Акчасын да бирделәр, чүп-чарын да җыештырып куйдылар. Шөкер, әнинең күршеләре Фазлыйәхмәтовлар да йортлы булды. Алар берәз соңрак йорт җиткереп чыкты.

Зөлфәт турында да язган идек. Әти-әниләре исән түгел инде аларның. Әмма төп йортка әзне суытмыйлар. Абыйсы белән Зөлфәт читтә эшләсә дә, гел кайтып торалар иде. Башка туганнары да бар. Барысы да балачаклары узган йортка җыела икән.

«Өчебезнең дә – үз тормышы. Абый белән мин өйләнмәгән әле. Чаллыда эшләсәк тә, туган йортка кайтып йөрдек. Мин командировкаларга йөргәч, төп туктау урыным авыл иде. Мондый хәлне күрербез димәгән идек. Бик авыр. Туган йортыбыздан берни калмады. Йорт урынына кечкенә генә булса да өй салырга иде инде», – дигән иде Зөлфәт безгә.

Бүген инде ул бик рәхмәтле һәм бәхетле. Үзләренә йорт салырга ярдәм иткән һәркемгә бары тик изге теләкләрен генә юллый. «Мондый хәсрәт берәүгә дә килмәсен», – дип теле ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ФЕРДИНАНД СӘЛАХОВ:
«КИЛЕР ЗАМАН: ТАКМАКТА ҮСКӘН БУЫН БЕЗГӘ КӨЛЕП КАРАР»

Киләчәк буын тамашачысы нинди булыр? Бүген җибәргән хаталар өчен ничек түләргә туры килер? Сәнгатьнең тәэсире, табышлар, югалтулар турында Татарстанның халык артисты, Илһам Шакиров исемендәге премия лауреаты Фердинанд СӘЛАХОВ белән сөйләштек.

:: Сезне шәхесләрне озату мәрасимнәрендә бик еш очратырга туры килә. Бер-бер артлы шәхесләр китә, аларга алмаш бармы?
– Филармониядә күп еллар эшләгәч, ул шәхесләрне яхшы беләм, шуңа күрә озату мәрасимнәрен алып баруны миңа йөклиләр. Кызганыч, тулы бер чор китә. Нишлисең, берәү дә мәңгелек түгел, кемдер китә, кемдер тәүге мәртәбә аваз сала. Берәү үлми берәү көн күрми, диләр бит. Радио-телевидениене кабызып, анда ниләр барганына күз салсаң, кемнәр көн күрә, кем урынына кем килә, дип уйланасың. Ләкин бу зарланып утыру түгел, бу – фактларны барлау. Дөрес, шәхесләр калдырган биеклекне тотарлык талантлар да бар. Бик көчле тавышлы җырчылар килде. Ләкин идеология, сәясәт юк. Катлаулы җырлар, халык җырларын башкарган җырчылар хәзер инде радио-телевидениегә кирәк түгел. Алар күңел ачу ягын сайладылар. Чөнки уйлый торган тамашачы ул – куркыныч тамашачы. Ә уйланырлык нәрсәләр бар. Әмма уйлатмас өчен бөтен нәрсә эшләнә. Шуңа талантлы яшьләр дә күңел ачу, такмак юлын сайлый.

Милләтнең сәнгате эстрада сәхнәсе белән генә чикләнми. Соңгы 20 елда бер булса да симфония тудымы икән? Мин 70 нче еллар башында консерваториягә килдем. Һәр елны Нәҗип Җиһанов, Фасил Әхмәт, гомумән, һәр композитор берәр симфония яки башка күләмле әсәр тәкъдим итә иде. Ә хәзер күләмле әсәрләр туамы? Хәзерге заман композиторлары дигәч, Эльмир Низамов, диләр. Мин аңа каршы кеше түгел, аның җырларын да җырлап карыйсым килә. Ләкин... җырлый алмыйм. Алар русча, ә мин җырласам, татарчалаштырам. Аннары инде ул Эльмир Низамовныкы булмый. Безнең Луиза Батыркаева белән шулай булды. Язып килә, җырлый башлыйм, бу минем җыр түгел, ди.

:: Композиторлардан Илһам Байтирәк, Миләүшә Хәйретдинова, башкалар да бар бит әле...
– Кайда соң алар? Мин бит, композиторлар юк, димим. Әмма аларны Казан урамы буйлап эзләп йөреп булмый бит инде. Радио-телевидение күрсәтергә, танытырга тиеш. Ә без аерылган-бүлгәләнгән. Без бер-беребезне белмибез. Бер казанда кайнасак та, бергә түгелбез. Бер караганда, интернет заманы, бер-береңне тап, яз, эшлә, иҗат ит кебек. Әмма интернет, төрле форум-чатлар игътибарны чит нәрсәгә җәлеп итү өчен генә. Зур әсәрне «Ватсап» аша аралашып кына язып булмый. Безнең бит бүген рояльгә кушылып җырлауны яздыра торган студия дә юк. Электрон студияләр хәттин ашкан, һич югы бер рояль торган студия юк. Элек радиокомитетта бар иде ул, анда консерватория студентлары язылды. Консерватория дигәннән. Анда ел саен җырчылар, композиторлар, хоровиклар, дирижерлар укып чыга. Ә алар турында һич югы бер тапшыру бармы? Аларны халык каян белсен ди?

> Без дөрес юнәлештә түгел. Татар сәнгате генә түгел, дөнья дөрес юнәлештә түгел. Бусы да – идеология булмау бәласе. Без инде, үз сәнгатебезне саклыйбыз дип, дөньядан аерылып яши алмыйбыз. Барыбыз да – зур бер казанда, һәм ул үзенчә кайный.

:: Шоу-бизнес дигән күренеш татар эстрадасын юкка чыгарды дисәк, килешәсезме?
– Килешми чара юк. Акча идарә иткән заманда яшибез. Хәзер артист дигәне үзе яза, үзе җырлый, үзе бии. Ә тамашачы шуны сәнгать дип кабул итә. Без радиодан «Мадам Баттерфляй», «Аида» операларының татарча вариантын тыңлап үстек. Хәзер андый тәрбия алып барылмый. Дөрес, техник яктан сәнгать тә, спорт кебек үк, үсә, үзгәрә, катлаулана бара. Әйткәнемчә, шул катлаулылыкларны күтәрерлек егет-кызлар да җитәрлек. Әмма алар җәмгыятькә кирәкми. Шуңа күрә консерватория белемлеләр дә ничарадан бичара такмакны сайлый.

Килер заман: такмакта үскән буын безнең чыгышлардан көлеп утырыр. Милләтне бетерер өчен, сәнгатен бетерергә кирәк, дип юкка гына әйтмәгәннәр бит. Ул – бик зур көч. Бер генә депутат та, бер генә корал да сәнгать кебек тәэсир итми, ул гына дуслаштыру-татулаштыру кодрәтенә ия. Туфан абый Миңнуллин әйткән иде бит әле: «Спорт, спорт дисез, футболдан чыгалар да бер-берсен үтергәнче сугышалар. Ә театрдан чыгып сугышканнарын күргәнегез бармы?» Хак сүзләр бит!

:: Репертуар сайлаганда нәрсәгә игътибар итәргә?
– Бонапарт, дәүләт эшлеклесенең йөрәге башында булырга тиеш, дигән. Йөрәк һәм баш белән уйлаганда төпле репертуар тупларга була. Зилә Сөнгатуллина әйтүенчә, җырчыга иң беренче чиратта акыл кирәк. Бер студент турында: «Материалы бар, үсәрме икән бу?» – дип сораган идем. Зилә: «Үсмәячәк, грамотасы юк», – диде. Шулай булды да. Репертуар сайлаганда үзеңне шәхес буларак әзерләргә кирәк. Бүген ашадым-эчтем, чабып йөрдем генә түгел, синнән соң нәрсә кала – әнә шуны кайгыртырга кирәк. Син – нинди милләт баласы? Әти-әниең кем, нәселең нинди – репертуар әнә шуны чагылдырырга тиеш. Бәлкем син Мәрҗаниләр нәселеннән чыккансыңдыр, ә репертуарың шырдыйбырдыйдан тора. Кызганыч, андыйлар да бар.

> Мин инде, бездә әле иман бар, дип сөенәм. Рус эстрадасын карагыз: анда да бит русча җырлаган кеше бетеп бара. Бөтен конкурслары инглиз телендә. Ул ниндидер бер чир кебек. Коронавирус килеп чыкты да, кешеләр саклану өчен битлек киеп йөри башлады. Сәнгатькә битлек кидертеп булмый. Шуңа чирли дә инде ул.

:: Эстрадада киенү рәвеше дә еш тәнкыйтьләнә. Сезнең исә образларыгыз үзенчәлекле. Аларны кем уйлап чыгара?
– Үзем уйлаштырам инде шунда. Бала вакыттан нужа тегәргә өйрәтте. Мин бит – энекәшләремә 13 яшемнән әти-әни урынына калган кеше. Оекбаш бәйләргә, әбигә күлмәк тегеп бирергә дә туры килде. Ә сәхнә костюмы ул – үзе бер сәнгать. Минем иҗатыма кайтсак, костюм ул – иҗатымның дәвамы. Аны уйлап табу өчен табигый сиземләү дә, матурлыкны күрә, аңлый, тудыра белү дә кирәк.

:: Мәскәү егете булып үссәгез, язмышыгыз нинди булыр иде икән?
– Мин аны әнкәйгә дә әйткәнем бар иде. Уенын-чынын бергә кушып: «Алып кайтмаган булсагыз, рус телле җырчы булган булыр идем, йөрмәгән булыр идем тирес башында җырлап», – дидем. «Картаймыш көнемдә, тегеләрен үстергәнсең, ә мине калдырып кайткансың, дип каршыма килерсең дип курыктым», – диде. Әле ярый алып кайтканмын, дип шөкрана кылып яшәде. Минем тәрбиядә яшәде, шөкер. Минем берминди үкенечем юк. Яшисен яшәдем, авырыйсын авырдым, тереләсен терелдем, җырлыйсын җырладым. Ходай Тәгалә ярдәм итте, юлымда яхшы кешеләр очрап торды.

Беренче операциягә 28 яшемдә кердем. Шунда Мәскәүдә бер кибеттә эшләгән хатын, минем өчен чын күңелдән теләк теләп, үзенчә яхшылык эшләптер инде, чукындырып калды. Операциядән чыкканны да көтеп алды.

:: Язмышыгыз бик гыйбрәтле. Начар авыруны да җиңгәнсез. Шундый чир белән көрәшүчеләргә үз мисалыгызда нинди киңәш бирер идегез?
– Вакытны сузарга ярамый. Сырхау барын белә торып яисә шикләнә торып, табибка бармау – бик зур хата. Авыру ул сигнал бирә, аңа игътибар итәргә кирәк. Медицина хәзер көчле. Әмма... Тагын шул проблема инде, тармак технологик яктан үссә дә, кадрлар кытлыгы бар. Чөнки уку түләүле. Түләүлегә «икеле»гә укучы да керә ала. Түләүле клиникада бер табибтан: «Син «икеле»гә укыдыңмы әллә?» – дип сораганым да булды. Нишләптер җавап бирмәде. Димәк, эзенә басканмын.

Яман шеш авыруын яшьли белдем. Шуннан, мин авырырга тиеш түгел, әле яшисем, җырлыйсым, балалар үстерәсем бар, дигән үҗәтлек кузгалды. Аңа карап кына исән калып булмый торгандыр, әмма мин әнә шундый оптимист, җилбәзәк булдым. Начар уйларга бирелмәү дә ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

:: Шәһәрме, авылмы – кайсы якынрак?
– ...

:: Шәһәр кешесе булганга, җавап бирү авырдыр.
– Әгәр язмышымда авыл булмаса, мин мондый җырчы була алмас идем. Моңны миңа авылым, әти-әнием бирде. Алар шул туфрактан чыкканга, авыл мохите, тәрбиясе, иман, дога кечкенәдән күңелгә иңгәнгә мин менә шушындый булып җитешкәнмендер. Иң сәламәт геннар – авылдан. Ул миннән беркайчан да

чыкмаячак. 50 ел Казанда яшим, аны дөньяның иң матур каласы саныйм һәм Казансыз тора алмыйм. Әмма мин – авыл баласы. Үзем шәһәрдә булсам да, күңелем авылда яши.

:: Бер интервьюда «үз исемемнән 22 яшемдә генә оялмый башладым» дигәнсез, сәбәбе нәрсәдә?

– Шундый исем кушканга гомер буе әтигә үпкәләп яшәдем. Ул – Бөек Ватан сугышы ветераны, аның андый исем кушуы, бер караганда, табигый да. Фердинанд исеме кыю, курку белмәс дигәнне аңлата. Әнием, вафатына берничә ел кала гына: «Сиңа исемне мин сайладым», – дип әйтте. Мәскәүдә күршедә Фердинанд исемле малай булган, шуннан күреп сайлаган икән. Нишләптер филармониядә дә исем белән эндәшмәделәр. Илһам абый Шакиров я улым, я Сәлах дип эндәшә иде. Әлфия апа Авзалова да Сәлах дип йөртте. «Мин Сәлах түгел, мин Фердинанд», – дигәч, «Кем кушкан сиңа бу эт кушаматын?» – ди иде, кулын селтәп. Үзем дә 22 яшемә кадәр исемемне әйтергә оялып йөрдем. Бик чибәр, Хәмзә исемле энем бар иде. Аны бөтен авыл яратты. Безнең икебезгә бер исем – Хәмзә булды. Татар авылында Фердинанд исеме хәтердә дә калмый, колакны да ерта, күрәсең, шуннан исемемне «онытканнар»дыр. Фердинанд исеменә армиядә ияләштем. Анда Алексеевск районыннан адаш белән хезмәт иттек. Кирәк бит, аның да апасы Фирдәвес исемле, минеке дә. Икебез дә – гаиләдә икенче балалар. Гаиләдәге төпчек балалар да бер исемдә иде. Шунда исемемә ияләшеп кайттым.

:: «Үзең бүләк» җырына карата фикерегез нинди?

– Ул заманында үтүктән генә яңгырамады инде, кайда да шуны җырлаттылар. Бу җырдан үзем дә арып киттем шикелле. Тапшыру әзерләгән радиожурналистлар: «Зинһар, ул җырыңны җырлама, 30 ел буе тыңлап туйдым», – диләр. Ә концертта шул җырны сорыйлар. Җырламасаң, шуның өчен генә килдем, ә син төшереп калдыргансың, дип үпкәлиләр.

:: Филармония ул – ...

– ...изге җир. Консерваториягә дә без Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова кебек җырчы булырга дип килдек. Дөньяда Паваротти дигән җырчы, Ла-Скала дигән театр барлыгын белмәдек. Илһам Шакиров авылга каян килә? Габдулла Тукай исемендәге филармониядән. Филармония безнең өчен кечкенәдән илаһи затлар эшли торган урын булды. 1981 елда Римма Ибраһимова белән беренче гастрольгә чыгып киттем. Шуннан соң инде кырык елдан артык вакыт узып китсә дә, филармония сүзе әле дә нык тәэсир итә.

:: Инде теләгемә ирештем дигәндә генә тавышыгыз өзелгән булса?..

– Андыйлар да бик күп. Минем коткаручым остазым Зөләйха Хисмәтуллина булды. Табибка да бит җитәкләп алып барды. Колагына: «Иң яраткан укучым», – дип пышылдады. Шуннан Мәскәү, операция. Мең тапкыр әйткәнем бар, хәзер дә кабатлыйм: минем өстемдә дога күп, шуңа исән калганмындыр. Өч әби белән үстем. Әни белән әтинең әниләре һәм караучысыз калган, үзебез тәрбиягә алган күрше әби белән яшәдек. Алар һәрвакытта миңа теләк теләде. Мин алар янында бөтерелеп үстем. Ул чакта нишләп гел теләк тели икән болар дип аптырасам, хәзер үзем шундыйга әйләндем. Шул догалар коткаргандыр дип уйлыйм. Бу табигый! Кешегә теләгән теләк ул материальләшә. Кеше ихластан сиңа теләк тели икән, ул сиңа килә.

:: Мөмкин булса, тормышыгызда нәрсәне үзгәртер идегез?

– Бернине дә үзгәртмәс идем. Мин кадерсезләнмәдем. Үземне кадерсезләргә ирек бирмәдем.

:: Халык хәтере кыскамы?

– Халык үзе дә кимеп бара бит ул. Хәтере белән бергә үзе дә китеп бара... Әмма онытылды дип бер шәхесне генә дә әйтә алмыйбыз. Инде оныттык дигәндә, тыелган Исхакый да кайтты бит! Җитәр шундый заман: кинәт кенә тагын бер олпатыбыз калкып чыгар. Яшәешнең кануннары шундый.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

АЙЗИРӘК ГӘРӘЕВА-АКЧУРА

(ХИКӘЯ)

КУЕНЫҢДА НИ БАР?

<Дәвамы. Башы 29 гыйнвар санында

Ир планшетыннан башын күтәрде, әле әрсез күгәрченгә, әле тын гына утырган өстәлдәшенә карады. Йөзендә елмаю күренде. Карт тиз-тиз тел очындагы сорауларын тезде:

– Әти-әниең исәнме? Әйбәтме?

– Исән-сау.

– Атың ни, улым?

– Илнур.

– Алай... Туристлар элек безгә килмиләр иде. Син каян килеп чыктың?

– Мин эш белән йөрим.

Мосафир шуны раслагандай, тавыш чыгарып алган планшетына киредән капланды. Инде күгәрченнәр өерләре белән килеп өстәлне бассалар да, аны эшеннән аера алмаслар кебек.

Мөнир карт янә шөкер кылды. Менә бит, татарчасы бар икән! Әйбәт кенә аңлаштылар! Йөрәк турысын-куенын сыйпап куйды. Мосафир мәшгуль утырганда, чәйчегә эндәште, тегесе ялт кына бушаган филҗаннарны алып китте, яңаларына чәй тутырып китерде. Ул арада мәчет картлары берәм-берәм кузгала башлады, плитә җәелгән җирлеккә бәргән таякларның тык-тык тавышлары ешаеп аерылды. Карт чәйне мосафир алдынарак этеп:

– Озаккамы? – дип сорады. Ни гаҗәп, егет планшетыннан аерылды.

– Берәр ай чамасы торам әле, – диде. Берничә йотымда чәен бушатты. Планшетын арка сумкасына тыгып куйды һәм картны аптыраштa калдырып, нәкъ төрекләр төсле:

– Мөсәгыйтегез олса, качтым, – диде. Ягъни «рөхсәт итсәгез, китәм».

– Киләсе җомгада кил.

Мосафир җавапка, ни әйе, ни юк димәде, янә елмайды. Мөселманлыкта йөргән шәкерт күңеле кисәтеп тора лабаса: ачык йөз, елмаеп сөйләшү сәдакага тиң. Карасу зәңгәр төстәге букчасын аркасына асты да мәчеттән ераклашты.

Аңа чыннан кызык иде. Менә хәзер китмәсә, ныграк ачылып китеп сөйләшсә... Ипи-тозлык татарчасы белән исәнлек-саулык сорарлык төрекчәсен кушканда, рәхәтләнеп гәпләшер! Әмма нидер, үзе дә аңламады, бу «кызык» белән кызыксынуны киртәләде, тизрәк китәргә, таныш түгел шәһәр урамнарында адашырга этәрде. Инсаннары, сүзләре, мөнәсәбәтләре белән бөтенләй башка үз дөньясына ианачы нык аның. Бары тик әлеге дөнья тышында калганнарны яратыргамы, алардан качаргамы, ераклашыргамы, якынаергамы – һәрвакыт төгәл бер карары юк. Карары, гадәттә, ихтыяҗга күрә туа.

Мөнир карт өчен бер атна искитмәле озын тоелды. Һәр көн иртәнге намазын кылганда мосафирның җомгага килүен Аллаһтан сорады. Намаздан соң үз алдына:

– Мәмләкәттән килгән... Нәкъ безнекеләргә охшап тора, татарчасы бар барын, никтер аз сөйләшә... Элеккеләр дә күп сөйләшмәс иде, – дип сөйләнде. Ятагына барып утыргач, якында гына торган өстәл өстеннән калын дәфтәрне хәтерләткән, шактый таушалган китапны үрелеп алды. Битләре коелып китмәсен өченме, иплән кенә ачты. Тигезле-тигезсез юллар булып яткан, иске имляда язылган җөмләләрне, дога әйткәндәй, көйләп укыды, ни гаҗәп, теленнән гарәпчә кәлимәләр түгел, татарча сүзләр төште.

«Аллаһым кичерсен, буш җирләргә шушы михнәтле юлыбызны кыскача аңлатып, язып барам. Күңелемне һәм аятьләр укып юатам, һәм шулар арасына түгәм. Авылдан чыгып киткәч, Кырымга поезд белән айга якын килдек. Менә шулай, Кырым җирләрен күрергә насыйп итте. Инде икенче ай үтеп бара. Күп вакыт җәяү китәбез. Бер җиргә тукталсак, янәбызга килеп-китүчеләр күп була. Кайберләре безнең ерактан килүебезне белеп алса, хәзер, җирлек җитәкчеләренә, әллә кемнәргә шикаять итәргә торалар. Шуңа күрә беркем күрмәсен өчен, юлларны чуалтып күп йөрибез. Көндезләрен урманнарда кача-поса агач төпләрендә утырабыз, төннәрен тик тормыйбыз, җәяүләп китәбез. Шушы Кырым җирен исән-имин үтеп, Кара диңгез буена барып җитәргә Аллаһым насыйп итсә иде, белмим, ул көннәрне күрербезме...»

Мөнир карт икенче битне ачты, бераз тын алды. Җыерчыклы кулы белән ачкан битне сыпырып куйды, шуннан соң кабат укуын дәвам итте.

«...Киткән вакытыбызда урын өстенә калган әтиебез, Аллаһым ярдәме илә, безне озатыр өчен капкага кадәр килде. Гыйлемле, мәшһүр затлар, әүкате бар кешеләр өчен мәҗлесләр җыйган йортыбыз янында кырыс холыклы әтиебез, бетешкән, ябык гәүдәсе белән бердәнбер кызына сыенып басып калды. Фатихасын алып киттек, аның гозерен Аллаһым биргән гомерем беткәнчегә кадәр аяк астына салмам, кардәшләремне ата кебек кайгыртырмын. Әмма, бичара апам, ялгыз башың көйле карт атабыз белән ничекләр михнәт тулы дөньяда баш чыгарсың?! Әүвәле юк, ахыры юк, бер сәламә дөнья бу... Һәр таң атканда шуларны уйлыйм, сезнең белән саубуллашып аерылышкан көнне искә төшереп сызланам. Үзгәем өзелә, әллә нинди караңгы, күңелсез уйлардан арынырга теләп, шушы юлдашлыгымны укыйм, күңелемне түгәм. Сиңа Аллаһтан ярдәмнәр сорап, догалар кылам. Ул сәхәрдәге кебек синең сөйләшүеңне беркайчан теләгәнем юк иде, шул капка төбендә безне озаткан яшьле күзләреңне яшергәнче, телгә килеп: «Мине калдырмагыз! Мине дә ияртеп алып китегез!» – дисәң иде. Ә син әтиебезгә ябыштың. Югыйсә әтиебез, бик камил зат, безгә көч-куәтен янә бер күрсәтеп, синең китүне хуплады. Санаулы көннәрем калды, диде. Безнең өйдән исән-сау чыгып китүебезне күрергә теләде. «Бүгенге заманда Аллаһыга күңел биргән, гавам өчен хезмәт итүне мәсләк иткән, мәдрәсә-мәчет әһеле булганнарның нинди мәшәкатьләргә һәм михнәтләргә дучар икәне мәгълүм. Улым, җан кошына мескен адәмдер кафәс (**читлек**)... Еракларга очыр җаныңны! Туганнарыңны сакла, харап итмәсеннәр. Син аларның өлкәне, гакылың, гыйлемең бар, иманың нык, алып кит аларны. Әүвәлгеләр китте, алар янына китегез, табыгыз юлын», – диде. Аның бөтен теләге, бәлки соңгы теләгедер дә, безнең исән-саулык. Әмма Миңзифа апа сине барыбер тыңлата алмады. Әти миңа ышанды. Мин исә шушы галәмәт озын, михнәтле юлда 16 яшьлек туганымның чыдамлыгына гаҗәпкә калам, 25 яшьлек туганыма рәхмәтләр укыйм, ул үз гаиләсен кайгырта, минем гаиләмә дә күз-колак. Алар миңа түгел, мин аларга таянам төсле, чөнки уемда мөшкел хәлдә калган бичара, кадерле һәм сөекле туганым Миңзифа апа... Карт атамның капка төбендә борынгылар сүзен искә төшерүе... Хәтергә уелган кадәресе шул.

Җан кошыга мескин адәмдер кафәс ***(читлек),***
Гакълыңа килгел, фәкыйрь, сән бер нәфәс... ***(сулыш...)***
Ятма, торгыл, үтте, күргел кафилә ***(кәрван),***
Бирмәгәйләр хисса һәргиз гафилә... ***(бирмәсләр өлеш һич тә гамьсезләргә...)***
Басмагыл юлыга рәһбәрсез кадәм ***(юлга җитәкчесез аяк басма),***
Башсыз юлы, үзе булгай көл-гадәм... ***(башсыз юлы, үзе бөтенләй юкка чыгар...)***
Рәхмәтең дәрьясыдин биргел өлеш ***(рәхмәтең дәрьясыннан бир өлеш),***
Тугры юлга биргел имди хуш йөреш... ***(тугры юлга бир имди хуш йөреш)***»

Укый-укый ятлап бетергәнгә, кайсыбер сәхифәләрне күңеленнән сагышлы бер көй белән әйтте. Гүя таң якынлашып килгән мәлдә, нindидер бер урман читендә, серле аксыл зәңгәр төстәге томан күтәрелгән аланлыкта ташка аркасын терәп утырган, арып йоклаган юлдашларын каравыллаган бабасының йомшак тавышы ишетелде.

Дәвамы бар >

Беләсең килсә...

1 Ленин бабай ничә яшьтә үлгән?
а) 53;
б) 63;
в) 73.

2 Ул тиз кабынучан, аннан ни көтәргә дә белмәссең:
а) холерик;
б) флегматик;
в) сангвиник.

3 «Запорожец» машинасын Финляндиядә нинди атама белән чыгарганнар?
а) «Анапа»;
б) «Сочи»;
в) «Ялта».

4 Боларның кайсы – балык?
а) кит;
б) акула;
в) дельфин.

Җаваплар: 1.а); 2.а); 3.в); 4.б).

Уйнаш уйлар

Яшьләр элеккеге түгел инде хәзер, диләр. Әбиләр дә элеккеге түгел инде хәзер: бөлеш пешермиләр, оекбаш бәйләмиләр, интернеттан чыкмыйлар.

***

Иртәгә нәрсә киясен кичтән уйлап куйган хатын иртән 2 сәгатькә озаграк йоклый.

***

Ни өчен бөтен кеше «А» пунктыннан «Б» пунктына бара? «А» пунктында хәлләр шулхәтле начар микәнни соң?

***

Күзләр өчен иң файдалы күнегү:
1) Күзләреңне йом.
2) Йокла.

***

Яхшы кешеләр бик аз калды. Саклагыз мине.

***

Баш мие: «Моны әйтәсе түгелдер инде...»
Авыз: «Ә мин әйтеп карыйм әле!»

***

Бөтен кеше һава торышыннан зарлана. Әйтерсең, һава торышыннан башка сезнең тормышыгызда бар да яхшы.

***

Программист эшне хатасыз тапшырса, бер тапкыр гына акча эшли. Ә хаталы тапшырса, даими акча эшли.

***

Кунаклар кирәгеннән артык җыелса, алар үзләрен хуҗа итеп тоя башлый.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: сабакташ, якташлык, Мисыр, Твикс, Ра, вагон, ихата, Аймәт, та, әрҗә, һич, Сатыш, алиһә, утлы, тиң, нәмә, Рәшидә, көтү, ил, тырнак, мескен, Элмәле, әләк, түзә, ир, аять, Чүкәй, гайка, тарантас, Рамазан.

Вертикаль: Сәйфиев, Римма, мәет, ата, әле, Гаташ, Иркә, Нәшид, ел, Әтнә, армут, иҗат, Карчыга, хәл, эре, ас, Әсфира, ит, Тукай, кат, һидаять, кырыс, аһәң, Айдар, эз, ачу, өйлә, ТНТ, Миләүшә, ым, Ли, кыерсыту, Әлдермештән.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758. Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 212

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+